СИШӘМБЕ
23 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 94 (5894)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—68, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—85, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Бөек бәйрәм алдыннан

Халыкара пролетариатның революцион бәйрәме булган Беренче Май якынлаша. Ватаныбызның хезмәт ияләре бу традицион көнне—Беренче Май бәйрәмен яңа уңышлар белән каршылау өчен ныклы көрәш алып баралар.

Социалистик төзелешнең барлык тармакларында җидди эш кайный. Бөек бәйрәм хөрмәтенә күп санлы һәм күп төрле бүләкләр хәзерләнә, яңа байраклар чигелә, ялкынлы лозунглар язылa, күп санлы плакатлар, диаграммалар хәзерләнә, шәһәр һәм авыл урамнары матур итеп бизәләләр, клублар, уку өйләре яңа постановкалар куярга, концертлар оештырырга хәзерләнәләр.

Завод, фабрикаларда, транспортта, колхоз, совхоз кырларында Беренче Май алды ярышы үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Күп санлы стахановчылар, ударниклар, күп станокчылар хезмәтнең җитештерүчәнлеген бер туктаусыз күтәрә барып, яңа җиңүләрне яулап алалар. **Бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек бәйрәмен—Беренче Майны яңа җиңүләр белән каршылыйк!** Социализм иленең эшчеләре, колхозчылары һәм барлык хезмәт ияләре Беренче Май ярышын әнә шул лозунг астында алып баралар.

Татарстан предприятиеләрендә Беренче Май алды ярышы 1940 нчы елның дүрт айлык планын срогыннан элек үтәү, колхоз кырларында язгы чәчү эшләрен иң кыска срокларда төгәлләү лозунгысы астында бара. Республикабызның күп кенә предприятиеләре һәм колхозлары бу лозунгны тормышка ашыру өчен көрәштә сокланырлык үрнәкләр күрсәтәләр. Дүрт айлык планны өч ай ярымда үтәгән Лаеш саз заводы, мехкомбинатның машина заводы коллективлары, 2 нче һәм 4 нче тегү фабрикалары, иртә чәчелә торган культураларны чәчү эшен 20 нче апрельгә тәгәлләгән „Кыска елга", „Свободный труд", „Яссы тугай" колхозлары (Ютазы районы), „Кызыл бүләк", „Трактор", „Корыч кул" һәм Парижская коммуна исемендәге колхозлар (Мослим районы), „Нептун", „Ишмән тау", „Таш елга", Чапаев һәм Тельман исемендәге колхозлар (Калинин районы) моның ачык мисале булып торалар.

Промышленность предприятиеләрендә, колхозларда һәм совхозларда, машина-трактор станцияләрендә социалистик ярыш дулкыны бер туктаусыз көчәя. Зур икади эш үзенең гүзәл җимешләрен көннән-көн һәркем һәм мул рак бирә. Стахановчылар һәм күп станокчылар сафлары яңа энтузиастлар исәбенә үскәннән-үсә бара. Киез итек-фетр фабрикасы эшчеләре Закирова һәм Хәйдарова иптәшләр, 14 нче трестның агач эшләү комбинаты эшчеләре Бачкисова һәм Әхмәтшина иптәшләр, Тәмте районының Буденный исемендәге колхоз членнары Буланкин, Чернова, Мошков һәм Михайлов иптәшләр кебек үзләренең нормаларын бер ярым—ике тапкыр арттырып үтәүче яңа стахановчылар саны көн саен артып тора.

Әйе, бөек бәйрәмгә зур бүләкләр хәзерләнә. Һәрбер завод, һәрбер фабрика, һәрбер колхоз, һәрбер учреждение һәм уку йорты Беренче Майны яңа уңышлар белән истә калдыру өчен көрәшә, тарихи бәйрәмне лаеклы рәвештә каршыларга хәзерләнә. Һәм бу аңлаешлы. Чөнки һәрбер уңыш, хәтта ул болай карауга кечкенә генә булып күренсә дә, җәмгыятьнең гомуми эшенә зур файда китергәнлекне, социализм төзелеше темпларын тагын да тизләтүгә ярдәм иткәнлекне безнең халкыбыз яхшы белә. Хуҗалыкның барлык тармакларында социалистик ярышның туктаусыз киңәюе, стахановчылар, күп станокчылар сафы көннән-көн үсү һәм шул нигездә хезмәтнең җитештерүчәнлеге өзлексез күтәрелә бару—менә болар барсы да аңлы хезмәтнең конкрет нәтиҗәләре, бөек партиябезгә һәм хөкүмәтебезгә ахрынача бирелгәнлекнең ачык чагылышы.

Ленин—Сталин партиясе тирәсенә, Совет хөкүмәте тирәсенә бер семьядәй нык тупланган безнең халкыбыз һәр төрле көрәшләргә хәзер тора. Ләкин бу әле масса активлыгына җитәкчелек эшен үз агымына куярга ярый дигән сүз түгел. Киресенчә, массада туган политик һәм производство активлыгына партия, профсоюз һәм комсомол оешмаларының җитәкчелекләрен тагын да көчәйтергә кирәк. Промышленность предприятиеләрен барсы да яхшы эшләгәннәре өчен, Татарстанның авыл хуҗалыгы үзенең артталыгын бетерсен өчен барлык чараларны күрергә, 1940 нчы елгы халык хуҗалыгы планын барлык тармаклар буенча уңышлы итеп үтәүгә ирешергә кирәк. Партия оешмалары һәм хуҗалык органнары җитәкчеләреннән әнә шул таләп ителә.

Зур дәрт һәм энтузиазм белән көтелгән Беренче Май көне якынлаша. Тагын бер атнадан илебезнең барлык шәһәрләре һәм авыллары күп санлы кызыл флаглар белән бизәләр, коммунизм биекләкләренә кыю рәвештә атлаучы совет кешеләренең горур тавышлары бөтен почмакларда яңгырар. Социалистик ярышта беренчелекне яулап алган хезмәт батырлары Беренче Май демонстрациясе колонналарында алгы сафларда булырлар. Беренче Май бәйрәме, безнең илебездә үткәрелә торган башка бәйрәмнәр шикелле үк, күп милләтле халыкларның туганлык тантанасы, данлыклы партиябезгә һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгәнлек тантанасы булыр.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Хәрби Диңгез Флотының гаскәри частьләрен һәм корабларын СССР орденнары белән бүләкләү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен бүләкләргә:

Кызыл байрак ордены белән

12 нче аерым истребительләр авиациясе эскадрилиясен,

13 нче аерым истребительләр авиациясе эскадрилиясен,

1 нче авиация полкының 3 нче эскадрилиясен,

„Щ - 324" су асты көймәсен.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль, 21 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Хәрби Диңгез Флотының начальниклар составына һәм кызыл флотчыларына Советлар Союзы Герое исеме бирү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен Советлар Союзы Герое исеме, Ленин ордены һәм „Алтын йолдыз" медале бирергә:

1. Батальонный комиссар Иван Иванович **Волосевичка.**
2. Кызыл флотчы Михаил Михайлович Гармозага.
3. Майор Георгий Петрович Губановка.
4. Капитан Алексей Антонович Гурбийга.
5. Майор Алексей Александрович Денисовка.
6. Капитан Петр Васильевич **Кондратьевка.**
7. 3 нче ранг капитаны Анатолий Михайлович **Коняевка.**
8. Өлкән лейтенант Анатолий Иванович **Нефедовка.**
9. Кызыл флотчы Александр Романович **Посконкинга.**
10. Кече командир Валентин Петрович **Пургинга.**
11. Өлкән лейтенант Федор Никифорович **Радуска.**
12. Майор Иван Георгиевич **Романенкога.**
13. Лейтенант Владимир Миронович **Савченкога.**
14. Майор Николай Александрович **Токаревка.**
15. Лейтенант Сергей Михайлович **Шуваловка.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 21 апрель 1940 ел.

Күн чималы хәзерләүне яхшырту чаралары турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары

Терлекчелекне тагын да үстерү, күн чималы базасын ныгыту һәм аяк киемнәре, шулай ук башка төрле күн һәм каеш әйберләр эшләп чыгаруны арттыру белән колхозларда һәм колхозчыларда күбрәк кызыксыну тудыру теләге белән ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

1. 1940 нчы елдан башлап, күн чималы хәзерләүнең хәзерге тәртибе урнына, колхозларның дәүләткә күн чималын колхозларга беркетелгән җир мәйданына (сөрү җирләренә, шул исәптән җимеш һәм яшелчә бакчаларына; болыннарга һәм көтүлекләргә) карап, ә колхозчыларның һәм ялгыз хуҗалыкчыларның һәрбер йорт башыннан мәҗбүри рәвештә тапшыруларын кертергә.

2. Колхозларга карата күн чималы тапшыруны түбәндәгечә исәпләргә:

а) 2 яштән югары булган мөгезле эре терлекләрдән—авырлыгы (чи килеш) 17 килограммнан артык булган эре тиреләр;

б) 1 яштән 2 яшькә кадәр булган мөгезле эре терлекләрдән—авырлыгы (чи килеш) 10 килограммнан 17 килогрммга кадәр булган уртача тиреләр;

в) дуңгызлардан — авырлыгы (чи килеш) 4 килограммнан артык булган тиреләр;

г) барлык нәселдәге сарыклардан яки кәҗәләрдән—кимендә 35 квадрат дециметр зурлыктагы тиреләр.

3. Республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен, колхозларга беркетелгән җир мәйданының (сөрү җирләренең, шул исәптән җимеш һәм яшелчә бакчаларының, болыннарның һәм көтүлекләрнең) һәрбер 100 гектарыннан колхозларның 1940—1941 һәм 1942 нче елларда дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруларының түбәндәге уртача еллык нормаларын билгеләргә:

А. МӨГЕЗЛЕ ЭРЕ ТЕРЛЕК ТИРЕЛӘРЕ (данәләр белән)

РЕСПУБЛИКАЛАР, КРАЙЛАР ҺӘМ ӨЛКӘЛӘР	1940 ел		1941 ел		1942 ел	
	Эреләре	Уртачалары	Эреләре	Уртачалары	Эреләре	Уртачалары
I. РСФСР						
Алтай крае	0,7	0,3	1,0	0,5	1,2	0,5
Архангельск өлкәсе	1,2	2,0	1,4	2,5	1,7	3,0
Башкыртстан АССР	0,7	0,3	1,0	0,5	1,2	0,5
Бурят-Монголия АССР	1,5	0,3	2,0	0,3	2,2	0,3
Вологда өлкәсе	1,0	1,5	1,4	2,0	1,5	2,0
Воронеж өлкәсе	0,6	0,3	1,0	0,4	1,0	0,5
Горький өлкәсе	0,7	0,4	1,0	0,5	1,5	0,6
Дагстан АССР	0,6	0,4	0,7	0,5	0,8	0,5
Иваново өлкәсе	0,8	0,6	1,0	0,9	1,5	1,0
Иркутск өлкәсе	1,2	0,5	1,5	1,0	1,5	1,0
Кабардино-Балкария АССР	1,2	0,5	1,8	0,5	2,4	1,0
Калинин өлкәсе	1,0	0,8	1,2	1,4	1,5	2,0
Калмык АССР	0,2	0,1	0,2	0,1	0,3	0,1
Киров өлкәсе	1,0	0,3	1,0	0,8	1,4	1,0
Коми АССР	1,5	1,2	2,5	2,0	4,0	3,0
Краснодар крае	1,5	0,5	1,5	0,5	1,5	0,5
Красноярск крае	0,9	0,6	1,0	0,7	1,2	0,8
Кырым АССР	0,7	0,3	1,0	0,5	1,2	0,5
Куйбышев өлкәсе	0,6	0,3	0,7	0,4	0,8	0,5
Курск өлкәсе	1,0	0,2	1,1	0,3	1,2	0,3
Ленинград өлкәсе	1,2	1,4	1,5	1,5	1,8	1,6
Мари АССР	0,7	0,5	1,1	0,8	1,3	1,0
Мордовия АССР	0,6	0,1	0,8	0,3	1,0	0,5
Мурманск өлкәсе	0,2	0,1	0,2	0,1	0,3	0,1
Москва өлкәсе	1,0	1,2	1,3	1,3	1,7	1,8
Волга буе немецләре АССР	0,4	0,3	0,4	0,3	0,7	0,4
Новосибирск өлкәсе	0,9	0,7	1,1	1,0	1,3	1,2
Омск өлкәсе	1,0	0,8	1,2	1,0	1,3	1,1
Орджоникидзе крае	0,8	0,4	0,8	0,4	1,0	0,4
Орел өлкәсе	1,0	0,5	1,2	0,6	1,5	0,8
Пенза өлкәсе	0,4	0,3	0,4	0,3	0,7	0,3
Молотов өлкәсе	1,0	1,0	1,1	1,1	1,4	1,2
Приморье крае	0,4	0,2	0,6	0,4	0,8	0,6
Ростов өлкәсе	1,0	0,4	1,1	0,4	1,2	0,4
Рязань өлкәсе	0,7	0,3	0,9	0,5	1,2	0,7
Саратов өлкәсе	0,4	0,2	0,5	0,2	0,6	0,3
Свердловск өлкәсе	1,0	1,2	1,1	1,3	1,4	1,4
Төньяк Осетия АССР	1,0	0,2	1,2	0,4	1,4	0,6
Смоленск өлкәсе	1,0	1,0	1,5	1,5	1,5	1,5
Сталинград өлкәсе	0,4	0,2	0,5	0,2	0,8	0,2
Тамбов өлкәсе	0,5	0,3	0,7	0,3	0,8	0,4
Татарстан АССР	0,7	0,2	0,9	0,3	1,0	0,5
Тула өлкәсе	0,9	0,5	1,1	0,7	1,3	1,0
Удмуртия АССР	0,7	0,5	0,9	0,6	1,2	0,7
Хабаровск крае	0,4	0,2	0,6	0,4	0,8	0,6
Чиләбе өлкәсе	0,5	0,6	0,8	0,7	1,0	0,8
Чечен-Ингушия АССР	0,6	0,3	0,7	0,4	0,7	0,5
Чита өлкәсе	0,6	0,5	0,8	0,5	0,9	0,7
Чкалов өлкәсе	0,5	0,2	0,6	0,3	0,7	0,3
Чувашстан АССР	1,2	0,4	1,3	0,6	1,4	0,8
Якутия АССР	0,2	0,1	0,2	0,1	0,2	0,1
Ярославль өлкәсе	0,8	0,8	1,0	1,0	1,4	1,4
II. Украина ССР	1,0	0,5	1,5	0,5	2,0	1,0
III. Белоруссия ССР	1,2	1,5	1,5	1,5	2,0	2,0
IV. Азербәйҗан ССР	1,0	0,3	1,1	0,4	1,2	0,5
V. Грузия ССР	2,0	0,4	2,2	0,6	2,4	0,8
VI. Әрмәнстан ССР	1,2	0,3	1,3	0,5	1,5	0,7
VII. Төркмәнстан ССР	0,5	0,1	0,5	0,1	0,6	0,2
VIII. Үзбәкстан ССР	0,8	0,1	1,0	0,2	1,1	0,3
IX. Таҗикстан ССР	0,7	0,2	0,9	0,3	1,0	0,5
X. Казагстан ССР	0,2	0,1	0,2	0,1	0,2	0,1
XI. Кыргызстан ССР	0,7	0,1	1,1	0,2	1,5	0,3
XII. Карел-Фин ССР	1,0	1,0	1,5	1,5	1,8	1,8

Б. ДУҢГЫЗ, САРЫК ҺӘМ КӘҖӘ ТИРЕЛӘРЕ (данәләр белән)

РЕСПУБЛИКАЛАР, КРАЙЛАР ҺӘМ ӨЛКӘЛӘР	Сарык һәм кәҗә тиреләре			Дуңгыз тиреләре		
	1940 ел	1941 ел	1942 ел	1940 ел	1941 ел	1942 ел
I. РСФСР						
Алтай крае	4,0	5,0	7,0	1,5	2,5	4,0
Архангельск өлкәсе	1,0	1,0	2,0	1,5	2,5	3,0
Башкыртстан АССР	2,5	5,0	6,0	1,5	2,5	3,0
Бурят-Монголия АССР	3,0	6,0	6,0	0,5	1,0	1,0
Вологда өлкәсе	0,6	2,0	2,0	1,5	2,5	3,0
Воронеж өлкәсе	3,0	5,0	6,0	2,5	5,0	7,0
Горький өлкәсе	1,2	1,5	2,5	2,0	4,0	5,0
Дагстан АССР	12,0	18,0	20,0	—	—	—
Иваново өлкәсе	1,5	1,5	2,0	2,0	3,0	4,0
Иркутск өлкәсе	2,0	3,0	3,5	1,0	2,5	3,5
Кабардино-Балкария АССР	8,0	12,0	14,0	1,0	1,5	2,0
Калинин өлкәсе	3,0	4,0	5,0	1,5	2,0	3,0
Калмык АССР	3,0	4,0	6,0	—	—	—
Кировск өлкәсе	0,6	1,0	1,5	1,5	3,0	4,0
Коми АССР	1,0	2,0	3,0	2,0	3,0	4,0
Краснодар крае	5,0	6,0	7,0	6,0	7,0	8,0
Красноярск крае	3,0	6,0	9,0	2,0	3,0	4,0
Кырым АССР	14,0	14,0	18,0	2,0	2,5	3,0
Куйбышев өлкәсе	1,5	3,0	4,0	1,5	3,0	4,0
Курск өлкәсе	2,0	4,0	6,0	4,0	5,0	7,0
Ленинград өлкәсе	1,5	2,0	3,0	2,0	3,0	4,0
Мари АССР	1,0	2,0	3,0	2,0	3,0	4,0
Мордовия АССР	2,0	2,5	3,0	2,0	5,0	6,0
Москва өлкәсе	2,0	3,0	3,5	2,0	3,0	4,0
Мурманск өлкәсе	0,4	0,5	0,5	0,5	0,5	0,5
Волга буе немецләре АССР	2,0	3,0	4,0	1,5	3,0	4,0
Новосибирск өлкәсе	3,0	4,0	5,0	1,5	2,5	4,0
Омск өлкәсе	2,5	5,0	6,0	2,0	3,0	4,0
Орджоникидзе крае	8,0	8,0	12,0	1,5	2,0	3,0
Орел өлкәсе	2,0	3,0	4,0	2,0	3,0	4,0
Пенза өлкәсе	1,5	2,0	3,0	1,0	1,5	2,0
Молотов өлкәсе	1,0	2,0	2,5	2,0	3,0	5,0
Приморье крае	0,4	0,5	0,5	0,5	0,5	0,5
Ростов өлкәсе	5,0	6,0	8,0	2,5	5,0	7,0
Рязань өлкәсе	1,8	2,0	2,5	1,5	3,0	4,0
Саратов өлкәсе	2,5	3,5	5,0	1,5	2,0	3,0
Свердловск өлкәсе	2,0	2,5	3,5	3,0	4,0	5,0
Төньяк Осетия АССР	14,0	15,0	18,0	0,5	0,5	1,0
Смоленск өлкәсе	2,0	4,0	5,0	1,0	3,0	5,0
Сталинград өлкәсе	3,5	5,0	6,0	0,5	1,0	2,0
Тамбов өлкәсе	1,5	4,0	6,0	2,0	3,0	4,0
Татарстан АССР	2,0	3,0	4,0	1,0	2,0	3,0
Тула өлкәсе	2,0	2,0	3,0	2,0	3,0	4,0
Удмуртия АССР	1,0	1,2	1,5	2,0	3,0	4,0
Хабаровск крае	0,4	0,5	0,5	0,5	0,5	0,5
Чиләбе өлкәсе	4,0	5,0	6,0	2,0	3,0	4,0
Чечен-Ингушия АССР	2,5	4,0	5,0	—	—	—
Чита өлкәсе	4,0	5,0	6,0	0,5	0,5	1,0
Чкалов өлкәсе	2,5	3,0	3,5	0,5	1,5	2,0
Чувашстан АССР	1,5	2,0	2,0	3,0	4,0	5,0
Якутия АССР	0,4	0,5	0,5	0,5	0,5	0,5
Ярославль өлкәсе	2,0	3,0	4,0	1,0	2,0	3,0
II. Украина ССР	3,0	4,5	5,0	5,0	6,0	7,0
III. Белоруссия ССР	3,0	4,0	5,0	2,0	4,0	6,0
IV. Азербәйҗан ССР	4,0	6,0	7,0	—	0,5	0,5
V. Грузия ССР	11,0	15,0	15,0	1,0	1,5	2,0
VI. Әрмәнстан ССР	7,0	10,0	14,0	0,5	1,0	1,0
VII. Төрекмәнстан ССР	25,0	30,0	40,0	—	—	—
VIII. Үзбәкстан ССР	12,0	18,0	22,0	—	—	—
IX. Таҗикстан ССР	12,0	12,0	16,0	—	—	—
X. Казагстан ССР	0,8	1,5	2,0	0,2	0,2	0,2
XI. Кыргызстан ССР	9,0	15,0	18,0	0,3	0,3	0,3
XII. Карел-Фин ССР	0,5	1,0	1,5	1,5	2,0	3,0

Казагстан, Кыргызстан, Азербәйҗан, Грузия, Әрмәнстан ССР, Башкыртстан, Татарстан, Дагстан, Кабардино-Балкария һәм Кырым АССР Совнаркомнарына, җирле шартларның нинди булуыннан чыгып аерым районнарда һәм колхозларда дуңгыз тиреләре тапшыруны сарык һәм кәҗә тиреләре белән алмаштырырга рөхсәт итәргә.

4. Колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга карата күн чималы тапшыруны түбәндәгечә исәпләргә:

а) дуңгызлардан—авырлыгы (чи килеш) кимендә 4 килограмм;

б) барлык нәселдәге сарыклардан яки кәҗәләрдән кимендә 35 квадрат дециметр зурлыгында.

5. 1940 һәм 1941 нче елга республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен һәрбер колхозчы йортыннан һәм ялгыз хуҗалыктан мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруның түбәндәгечә уртача еллык нормаларын билгеләргә (данәләр белән):

Өлкәләр, крайлар һәм республикалар	Колхозчы йортлары		Ялгыз хуҗалыклар	
	Сарык һәм кәҗә тиреләре	Дуңгыз тиреләре	Сарык һәм кәҗә тиреләре	Дуңгыз тиреләре
I. Архангельск өлкәсе Мурманск өлкәсе Карел-Фин ССР Ленинград өлкәсе Вологда өлкәсе Калинин өлкәсе Ярославль өлкәсе Горький өлкәсе Иваново өлкәсе Смоленск өлкәсе Москва өлкәсе Тула өлкәсе Рязань өлкәсе Орел өлкәсе Курск өлкәсе Воронеж өлкәсе Тамбов өлкәсе Пенза өлкәсе Мордовия АССР Чувашстан АССР Мари АССР Удмуртия АССР Киров өлкәсе Молотов өлкәсе Свердловск өлкәсе Коми АССР Якутия АССР Приморье крае Хабаровск крае	0,5	0,5	1,0	0,5
II. Белоруссия ССР Ростов өлкәсе Орджоникидзе крае (Карачай һәм Черказ автономияле өлкәләрдән тыш) Сталинград өлкәсе Саратов өлкәсе Волга буе немецләре АССР Куйбышев өлкәсе Чкалов өлкәсе Иркутск өлкәсе Бурят-Монголия АССР Чита өлкәсе	0,5	1,0	1,0	1,0
III. Грузия ССР Төньяк Осетия АССР Чиләбе өлкәсе Омск өлкәсе Новосибирск өлкәсе Алтай крае (Ойротия автономияле өлкәсеннән тыш) Красноярск крае (Хакас автономияле өлкәсеннән тыш)	1,5	1,0	2,0	1,0
IV. Украина ССР Краснодар крае (Адыгей автономияле өлкәсеннән тыш)	—	1,0	—	1,5
V. Үзбәкстан ССР Кабардино-Балкария АССР Орджоникидзе краеның Карачай һәм Черкас автономияле өлкәләре Татарстан АССР Красноярск краеның Хакас автономияле өлкәсе Алтай краеның Ойротия автономияле өлкәсе	1,0	—	1,5	—
VI. Кыргызстан ССР Таҗикстан ССР Төркмәнстан ССР Казагстан ССР Башкыртстан АССР Калмык АССР Дагстан АССР Чечен-Ингушия АССР Азербәйҗан ССР Әрмәнстан ССР Кырым АССР	2,0	—	3,0	—

6. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру буенча республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен билгеләнгән нормаларны, кагыйдә буларак, тиешле өлкәләрнең, крайларның һәм республикаларның барлык районнары өчен кулланырга. Хәзерләүләр Наркоматына, аерым тәртиптә, хезмәт ияләре депутатларының өлкә (край) советлары башкарма комитетларының һәм республика совнаркомнарының үтенүе буенча, аерым районнар өчен, нормаларны арттыру яки киметү ягына таба үзгәртергә рөхсәт итәргә, ләкин мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру буенча шушы карар белән өлкә, край, республика өчен билгеләнгән еллык уртача өлкә нормасы әлбәттә сакланырга тиеш.

7. Аерым колхозларга карата, Наркомзагның өлкәләрдәге, крайлардагы һәм өлкәләргә бүленми торган республикалардагы уполномоченныйларының раславы белән, дәүләткә күн чималы

(ДӘВАМЫ 2 нче БИТТӘ).

Күн чималы хәзерләүне яхшырту чаралары турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары

(АХРЫ. БАШЫ 1 нче БИТТӘ).

тапшыру буенча район өчен билгеләнгән еллык норманы 30 процентка кадәр арттырырга яки киметергә рөхсәт итәргә, ләкин күн чималы тапшыру буенча район өчен билгеләнгән уртача норма районда әлбәттә үтәлергә тиеш.

8. Колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга карата, суелган һәм йогышсыз авырулардан үлгән мөгезле эре терлекләрдән алына торган барлык тиреләрне хәзерләү оешмаларына мәҗбүри рәвештә сатарга дип билгеләргә.

9. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр, промысло, балык тоту артельләренең һәм инвалидлар кооперациясе артельләренең членнары, суелган һәм йогышсыз авырулардан үлгән мөгезле эре терлекләрдән, сарыклардан, кәҗәләрдән һәм дуңгызлардан алына торган бөтен күн чималын дәүләтнең хәзерләү оешмаларына сатарга тиешләр дип билгеләргә.

10. СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында“ 1939 нчы ел 8 нче июль карарының 27 нче пункты буенча дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит тапшыруга тартылмаучы хуҗалыклар мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруга тартылмыйлар дип билгеләргә.

Бу хуҗалыкларда терлекләр булса, бу хуҗалыклар үзләренең суела торган терлекләренең тиреләрен билгеләнгән сатып алу бәяләре буенча хәзерләү оешмаларына сатарга тиешләр.

11. Сезонлы эштә эшләүче яки обязательстволар тапшырылган вакытка даими эштә бер елдан ким эшләгән ялгыз хуҗалыкчылар дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруга ялгыз хуҗалыклар өчен билгеләнгән нормалар буенча тартылалар.

12. Авыл җирләрендә һәм дача поселкыларында торучы һәм каралты тирәсе җирләре яки кыр участкылары булган ялгыз кустарьлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруга шул районнардагы ялгыз хуҗалыклар өчен билгеләнгән нормалар буенча тартылалар.

13. Колхозлар, колхозчы йортлары һәм ялгыз хуҗалыклар дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшырганда чималның бер төрен икенчесе белән түбәндәгечә алмаштыруга юл куярга:

а) мөгезле эре терлекнең 25 килограммнан артык авырлыктагы бер тиресе тапшырулар берәмлеге итеп алынган 1,5 эре тирегә яки 3 уртача тирегә исәпләнә;

б) мөгезле эре терлекнең 17 килограммнан 25 килограммга кадәр авырлыктагы бер тиресе (эре тире) тапшырулар берәмлеге итеп алынган 1,5 уртача тирегә исәпләнә;

в) мөгезле эре терлекнең 6 килограммнан 10 килограммга кадәр авырлыктагы ике тиресе 1 уртача тирегә исәпләнә;

г) ат, дөя һәм ишәк тиреләре, шулай ук качыр тиреләре үзләренең авырлыкларына карап, мөгезле эре терлек күн чималы тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәү исәбенә исәпләнәләр;

д) 3 дуңгыз тиресе яки 4 сарык тиресе, яисә 4 кәҗә тиресе 1940 һәм 1941 нче елларда 1 уртача тирегә исәпләнәләр;

е) авырлыгы 4 килограммнан ким булган 2 дуңгыз тиресе 1940 һәм 1941 нче елларда авырлыгы 4 килограммнан артык булган 1 дуңгыз тиресенә исәпләнә;

ж) авырлыгы 4 килограммнан артык булган 1 дуңгыз тиресе билгеләнгән күләмдәге 1 сарык яки 1 кәҗә тиресенә исәпләнә;

з) конрактация договорлары буенча колхозлар һәм колхозчылар тарафыннан Наркомзагның „Заготживсерье“сына тапшырыла торган каракуль тиреләре 1 сарык тиресенә 1 каракуль тиресе исәбеннән дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруга исәпләнәләр;

и) 1 болан тиресе Мурманск өлкәсендә, Якутия АССР да һәм ерак төньяк районнарында 2 дуңгыз тиресенә яки ике сарык тиресенә исәпләнә.

14. Колхозларның мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруларны үтәүләре вактында эре тиреләрне уртача яки вак тиреләр белән алмаштыруларын тыярга.

Колхозларның мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыруларны үтәгән вакытларында, кагыйдә буларак, дуңгыз тиреләрен күн чималының башка төрләре белән алыштыруларына юл куелмый. Әгәр дуңгыз тиреләре булмаса, алыштыруга район уполнаркомзагы рөхсәте белән юл куела.

Колхозлардан мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру исәбенә авырлыгы 6 килограммнан ким булган бозау тиреләре кабул ителми.

Мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру исәбенә бары тик тоташ тиреләр генә кабул ителә.

15. Куе йонлы һәм ярым куе йонлы сарык тиреләре тапшыру дәүләткә сарык һәм кәҗә тиреләре тапшыру йөкләмәләрен үтәүгә исәпләнәләр. „Голяк“ сарык тиреләре йөкләмәләрне үтәү исәбенә исәпләнмиләр. Шулай ук ярты яшькә кадәр булган сарык һәм кәҗә бәтиләренең 35 квадрат дециметрдан ким булган тиреләре дә дәүләткә сарык һәм кәҗә тиресе тапшыру йөкләмәләрен үтәү исәбенә кермиләр.

16. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру исәбенә түбәндәгеләр керәләр:

а) дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшыру яки тере үлчәүдә дәүләткә ит сату тәртибендә тапшырылган мөгезле эре терлекләрнең, дуңгызларның, сарыкларның һәм кәҗәләрнең тиреләре (терлекнең сан исәбенә карата). Бу вакытта мөгезле эре терлек тиреләренең категорияләрен (авырмы, эреме, уртачамы, вакмы икәнлеген) билгеләү өчен тере үлчәүнең 7% ы, ә дуңгызлар буенча 6—5% ы исәбеннән чыгып эш итәргә;

б) суелган һәм йогышсыз авырулардан үлгән терлекләрдән тапшырыла торган тиреләр.

Тиреләр, гамәлдәге стандартларга туры китереп, төрлечә хәзерләнгән хәлдә кабул ителәләр.

17. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру буенча йөкләмәләр исәбенә I нче һәм II нче сорт тиреләр кабул ителә. Йөкләмәләрне үтәү исәбенә түбән сортлы күн чималы тапшырылганда III нче сорт тире тапшыру нормасыннан 25% ташлама белән һәм IV нче сорт тире тапшыру нормасыннан 35% ташлама белән исәпләнә.

18. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәгәннән соң һәм терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планының үтәлүен тәэмин иткәннән соң колхозлар калган тиреләрдән үзләре белгәнчә файдаланырга хаклы булалар, дип билгеләргә.

19. Мәҗбүри рәвештә күн чималы һәм ит тапшыру йөкләмәләрен үтәгән һәм терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планының үтәлүен тәэмин иткән колхозларга мөгезле эре терлек тиреләрен (авырлыгы 6 килогрммнан артык булмаганнарны), дуңгыз һәм сарык тиреләрен дәүләт һәм кооператив предприятиеләрендә эшкәртергә рөхсәт итәргә. Колхозлар эшкәртү өчен бары тик җәмагат терлекчелегеннән алынган күн чималын гына тапшырырга хаклы булалар.

20. Дәүләткә мәҗбүри рәвештә күн чималы тапшыру йөкләмәләрен үтәгәннән соң һәм дәүләткә ит тапшыруны үтәсәләр колхозчылар һәм ялгыз хуҗалыкчылар калган дуңгыз һәм сарык тиреләреннән үзләре белгәнчә файдаланырга хаклы булалар һәм аларны шушы карарда күрсәтелгән шартларда дәүләт һәм кооператив предприятиеләрендә эшкәртә алалар.

Колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга сарык, кәҗә һәм дуңгыз тиреләрен эшкәртүгә тапшырырга хокук бирергә.

21. Күн чималын эшкәрткән өчен аны тапшыручы алынган товарның бәясен дәүләтнең ныклы бәяләре буенча акчалата түли дип билгеләргә, эшкәртергә бирелгән күн чималының бәясен дәүләтнең сатып алу бәяләре буенча чигереп калырга, шулай ук түбәндәге исәптән чыгып натуралата түли дип билгеләргә:

а) мөгезле терлек һәм дуңгыз тиреләрен эшкәрткән өчен шуннан алынган әзер продукциядән натуралата колхоз 35% түли;

б) 2 сарык тиресен эшкәрткән өчен тапшыручы эшләнеп җиткән 1 сарык тиресе ала.

22. Мәҗбүри рәвештә күн чималын тапшыруны үтәгәннән соң һәм дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит тапшыруны үтәгәннән соң тапшыручылар түбәндәге исәп буенча дәүләт куйган ныклы бәяләр белән күн товарлар алалар:

а) колхозлар—дәүләткә сатылган терлекләрнең (мөгезле эре терлекләрнең һәм дуңгызларның) тиреләре өчен шуннан чыккан әзер продукциягә карата натуралата 75 процент күләмендә һәм дәүләткә сатылган 2 сарык тиресе өчен 1 әзер тире;

б) колхозчылар—дәүләткә сатылган дуңгызларның тиреләре өчен шуннан чыккан әзер продукциягә карата натуралата 70 процент күләмендә һәм дәүләткә сатылган сарыкларның 2 тиресе өчен эшләнгән әзер 1 тире.

23. Әгәр колхозчылар һәм ялгыз хуҗалыкчылар дәүләткә мөгезле эре терлек сатсалар, алар сатылган терлекләрнең тиреләре өчен, шуннан чыккан әзер продукциягә карата, дәүләт куйган ныклы бәяләр белән, натуралата 15 процент күләмендә күн товарлары алалар.

24. Колхозларга, колхозчы йортларына һәм ялгыз хуҗалыкларга күн чималын дәүләткә алдагы елгы мәҗбүри тапшырулар исәбенә аванс тәртибендә тапшырырга рөхсәт ителә.

25. Райуполнаркомзагларга, 1940 нчы елның башыннан алып шушы карар чыкканчыга кадәр колхозларның, колхозчы йортларының һәм ялгыз хуҗалыкларның күн чималы хәзерләүчеләргә („Союззаготкож“ га, потребкооперациягә, промкооперациягә һәм инвалидлар кооперациясенә) тапшырылган күн чималын, шулай ук колхозларның һәм аерым хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит тапшыру һәм дәүләткә сату тәртибендә 1940 нчы елның 1 нче январеннан башлап хәзерләү оешмаларына тере килеш тапшырган мөгезле эре терлек, дуңгыз һәм сарык тиреләрен 1940 нчы елны күн чималы тапшыру йөкләмәләрен үтәү исәбенә исәпләргә рөхсәт итәргә.

Күн чималын мәҗбүри рәвештә тапшыруга тартыла торган колхозларга һәм башка хуҗалыкларга карата, күн чималы тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәү исәбенә исәпләүне, шушы карар белән билгеләнгән тәртиптә, күн чималының яки тере терлекнең хәзерләү оешмаларына кабул ителүе турында тапшыручылар тарафыннан тиешле документлар күрсәтелгән вакытта үткәрергә. Күн чималын мәҗбүри тапшырулар исәбенә исәпләү срогын шушы карар игълан ителгән көннән алып ике айлык итеп билгеләргә.

26. Наркомзагның „Заготживсырье“ сын һәм Центросоюзны,—дәүләт өчен күн чималы сатып алуны оештырырга мәҗбүр итәргә. Дәүләт өчен сатып алуны түбәндәге шартларда үткәрергә:

а) колхозлар, колхозчы йортлары һәм ялгыз хуҗалыклар күн чималын мәҗбүри рәвештә тапшыруга нинди төр чимал буенча тартылсалар, шул чималны дәүләткә саткан вакытта аларга күн товарларын, эшкәртү өчен тапшырганда билгеләнгән шартларда, ягъни шуннан чыккан әзер продукциягә карата натуралата 65 процент күләмендә сатарга;

б) колхозлар, колхозчы йортлары, ялгыз хуҗалыклар, шулай ук эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хуҗалыклары дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшырылмый торган күн чималын дәүләткә сатканда аларга күн товарларын, әгәр дә терлекне бойня площадкаларында суйган яки хәзерләү оешмаларының терлек суючыларыннан суйдырткан булсалар, әзер продукциягә карата 10 процент күләмендә, ә сатып алынган тире ишек алдында суелган терлекнеке булса дуңгыз тиреләре өчен күн товарларын әзер продукциягә карата 10 процент күләмендә һәм мөгезле эре терлек һәм башка терлек тиреләре өчен 5 процент күләмендә сатарга;

в) сарык тиреләре сатып алганда эшкәртелмәгән ике сарык тиресе өчен бер әзер тире сатарга.

Мәҗбүри тапшырулар буенча тапшырылырга тиеш булган яки башка төр тире белән алыштырырга мөмкин булган күн чималын дәүләткә бары тик күн чималын дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшыруны үтәгән хуҗалыклардан гына сатып алырга.

27. Совхозлар, дәүләт һәм кооператив оешмаларының ярдәмче хуҗалыклары, җәмагат туклануы оешмалары һәм хәрби частьләр үзләрендә суелган һәм йогышсыз авырулардан үлгән мөгезле эре терлекләрнең, атларның, дөяләрнең, сарыкларның, кәҗәләрнең һәм дуңгызларның барлык тиреләрен Наркомзагның „Заготживсырье“ сына тапшырырга тиешләр дип билгеләргә.

Күн чималы тире туналганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

28. Һәрбер колхозның мөгезле эре терлек фермаларында, минимум сандагы сыерлар белән берлектә, эш үгезләреннән тыш, колхозларга беркетелгән җир мәйданы (сөрү җире, шул исәптән җимеш һәм яшелчә бакчалары, болыннар һәм көтүлекләр) исәбеннән чыгып, кимендә 2 яшькә кадәр булган (ит өчен һәм авыр тиреләр алу өчен суярга үстерелгән) печелгән яш үгезләр минимумы булырга тиеш дип билгеләргә:

а) Белоруссия ССР, Украина ССР, Башкыртстан АССР, Кырым АССР (көньяк яр буендагы районнардан тыш), Төньяк Осетия АССР, Коми АССР, Волга буе немецләре АССР, Кабардино-Балкария АССР, Бурят-Монголия АССР, Калмык АССР, Якутия АССР, Алтай, Красноярск, Орджоникидзе һәм Краснодар крайлары, Иркутск, Новосибирск, Омск, Көнчыгыш Казагстан, Җамбул, Симипалат, Гурьев, Көнбатыш Казагстан, Акмолинск, Төньяк Казагстан, Алма-Ата, Актүбә, Караганды, Кустанай, Павлодар, Куйбышев, Архангельск, Вологда, Чкалов, Саратов, Сталинград, Ростов, Молотов, Свердловск, Чиләбе һәм Чита өлкәләре колхозларында — җир мәйданы 200 гектарга кадәр булганда кимендә 2 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 200 гектардан артык булганда, ләкин 500 гектардан артык булмаганда кимендә 4 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 500 гектардан артык булганда, ләкин 1.000 гектардан артык булмаганда кимендә 10 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 1.000 гектардан артык булганда, ләкин 2.000 гектардан артык булмаганда кимендә 15 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 2.000 гектардан артык булганда, ләкин 3.000 гектардан артык булмаганда кимендә 20 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 3.000 гектардан артык булганда кимендә 25 печелгән яш үгез;

б) Кыргызстан ССР, Азербайҗан ССР (субтропик культуралар районнарыннан тыш), Грузия ССР (Көнбатыш Грузия районнарыннан тыш), Әрмәнстан ССР, Карел-Фин ССР, Приморье һәм Хабаровск крайлары, Воронеж, Горький, Иваново, Калинин, Москва, Ленинград, Курск, Көньяк Казагстан, Орел, Пенза, Рязань, Тамбов, Тула, Смоленск һәм Ярославль өлкәләре колхозларында—җир мәйданы 150 гектарга кадәр булганда кимендә 2 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 150 гектардан артык булганда ләкин 400 гектардан артык булмаганда кимендә 3 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 400 гектардан артык булганда, ләкин 800 гектардан артык булмаганда кимендә 8 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 800 гектардан артык булганда, ләкин 1.500 гектардан артык булмаганда кимендә 15 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 1.500 гектардан артык булганда кимендә 20 печелгән яш үгез;

в) башка республикалардагы, крайлардагы һәм өлкәләрдәге колхозларда—җир мәйданы 120 гектарга кадәр булганда кимендә 1 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 120 гектардан артык булганда, ләкин 200 гектардан артык булмаганда кимендә 2 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 200 гектардан артык булганда, ләкин 500 гектардан артык булмаганда кимендә 3 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 500 гектардан артык булганда, ләкин 1.000 гектардан артык булмаганда кимендә 5 печелгән яш үгез;

Җир мәйданы 1.000 гектардан артык булганда кимендә 9 печелгән яш үгез.

Зур шәһәрләрне өсте алынмаган сөт белән тәэмин итәргә кирәклекне искә алып, Москва шәһәре тирәсендә 100 километрлы зонада, Ленинград шәһәре тирәсендә 75 километрлы зонада, Киев һәм Харьков шәһәрләре тирәсендә 50 километрлы зонада, Сталино, Днепропетровский, Одесса, Баку, Ростов-Дон, Горький, Свердловск, Чиләбе, Минск, Хабаровск һәм Владивосток шәһәрләре тирәсендә 25 километрлы зонада печелгән яш үгезләр үстерү минимумы билгеләмәскә.

29. Фермалардагы печелгән яш үгезләр санының шушы карар белән билгеләнгән минимумы колхозларда 1942 нче елдан соңга калмыйча үтәлергә тиеш, ә 1941 нче елның ахрына кадәр фермаларда печелгән яш үгезләр саны билгеләнгән минимумның кимендә 50 процентына җитәргә тиеш. Моның өчен колхозларга фермаларда, 1939 һәм 1940 нчы елларда туган яш үгезләрне 1941 һәм 1942 нче еллар өчен билгеләнгән печелгән үгезләр санының минимумын тулысынча тәэмин итәрлек санда аерып куярга, ә кирәк кадәр санда яш үгезләре булмаган колхозларга аларны сатып алырга.

30. СССР Наркомсовхозы совхозларында печелгән яш үгезләр санын (2 яшькә кадәр үстереп җиткерү өчен) 1942 нче елның азагына кимендә 170 мең башка, СССР Наркомпищепромы совхозларында 25 мең башка, СССР Наркомвнешторгы совхозларында 5 мең башка, СССР Наркоммясомолпром совхозларында 5 мең башка җиткерергә.

31. Барлык совхозларга, яш ярымнан түбән булган мөгезле яш эре терлекләрне суюны тыярга, бу, шәһәр тирәсеннән 50 километр зонада урнашкан сөт совхозларына кагылмый.

32. Сарыкларның йонын аларны суюдан ике ай элек кыркуны тыярга.

33. Нечкә йонлы сарык асраучылык зоналарындагы колхозларда һәм колхозчыларда тиресе тунга китә торган сарыклар үрчетүгә юл куярга, ләкин нечкә йонлы көтүләрне тупас йонлы сарык көтүләреннән аерым үрчетү һәм аерым тәрбияләү тәртибен бик нык сакларга.

34. Кәҗәләре генә булган эшчеләр һәм хезмәткәрләр хуҗалыкларын дәүләткә мәҗбүри рәвештә ит тапшырудан азат итәргә.

Колхозчылар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр йортларын сөтле кәҗәләр саны буенча дәүләткә кәҗә йоны тапшырудан азат итәргә.

35. Наркомзагның „Заготживсырье“ сына һәм Центросоюзга,—терлек сую пунктлары санын 1942 нче ел ахрына 25 меңгә җиткерергә.

Наркомзагның „Заготживсырье“ сына һәм Центросоюзга терлек сую пунктларыннан ерак булган авыл җирләрендә терлекләрне колхозларда һәм колхозчыларның йортларында терлек суючы махсус кешеләрдән суйдыртырга.

36. СССР Наркоммясомолпромын,—ит комбинатларында, терлек сую урыннарында һәм терлек базаларында терлекләрне суяр алдыннан тәрбияләүне күзәтү өчен ветеринария инспекторы контроле оештырырга мәҗбүр итәргә.

37. СССР Норкомземын, СССР Наркомсовхозын, союзный һәм автономияле республикаларның совнаркомнарын, хезмәт ияләре депутатларының өлкә (край) советлары башкарма комитетларын,—1940 нчы елдан башлап барлык хуҗалыкларда, мәҗбүри рәвештә, мөгезле эре терлекләрне украдан системалы рәвештә чистарту үткәрүне тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе
В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре
И. СТАЛИН.

20 апрель, 1940 ел.

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ ПЛЕНУМЫ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА

ПАРТИЯНЕҢ ШӘҺӘР АКТИВЫ ҖЫЕЛЫШЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы йомгаклары турында ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш Алемасовның докладын тыңлап тикшергәннән соң, Казан шәһәренең партия активы җыелышы ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы карарларын тулысынча яхшы дип таба.

Илебезнең тышкы политикасында ирешелгән гаят зур уңышлар—алар партиянең XVIII нче съездында тышкы политика өлкәсендә иптәш Сталин куйган бурычларны тормышка ашыруда партиянең, хөкүмәтнең һәм бөтен совет халкының армый-талмый эшләүләренең нәтиҗәсе.

Сталинчыл тышкы политиканы эзлекле рәвештә үткәреп, партиябез һәм Совет хөкүмәте „Советлар Союзының бер кайчан да чит политика коралы булмаганлыгын һәм булмаячагын, башка илләрдәге әфәнделәргә ошавы яки ошамавы белән хисаплашмастан СССР ның үз политикасын үткәреп килгәнлеген һәм үткәрәчәген“ бөтен дөньяга күрсәтте. **(Молотов).**

Безнең батыр Кызыл Армиябез һәм Хәрби Диңгез Флотыбыз, СССР ның төньяк-көнбатыш чикләрендә гүзәл җиңүләргә ирешеп, күп кенә капиталистик илләрнең берләшкән көчләрен тар-мар итеп, Ленинградка, Мурманск шәһәренә һәм Мурманск тимер юлына куркынычсызлыкны тәэмин иттеләр һәм социализм иленең куәтен һәм җиңелмәслеген бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Казан шәһәренең партия активы 1940 нчы елны илебезнең оборона кирәкләренә 57 миллиард сум акча җибәрү турында СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе карарын гаят зур канәгатьләнү белән котлый. Социалистик Ватаныбызның куркынычсызлыгы турында, бөек совет халкының яхшы тормышы һәм тыныч хезмәте турында бу Сталинчыл кайгыртучанлык Татарстан республикасының барлык партияле һәм партиясез большевикларын Ватаныбызның оборона сәләтен армый-талмый ныгытырга, Кызыл Армиябезне һәм Хәрби Диңгез Флотыбызны тагын да зуррак игътибар белән чолгап алырга, предприятиеләрдә һәм колхозларда социалистик ярышны киңәйтергә мәҗбүр итә.

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр турында ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы карары безнең социалистик халык хуҗалыгын үстерү өчен яңа киң мөмкинлекләр ача. Колхоз хуҗалыгының тагын да үсүенә һәм чәчәк атуына, илебездә авыл хуҗалыгы продуктларына һаман үсеп бара торган сорауларны тулысынча канәгатьләндерүгә ярдәм итү ягыннан бу карарның тарихи әһәмияте бар.

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр партиянең Татарстан оешмасы алдына авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүне тамырыннан яхшыртудан гыйбарәт булган җидди бурычлар куялар. 1940 нчы елны югары иген уңышы өчен, язгы чәчүне уңышлы үткәрү өчен көрәш колхозчыларның киң катлау массасын ВКП(б) Үзәк Комитетының соңгы март пленумы карарларын үтәүгә туплау билгесе астында үтәргә тиеш.

Терлекчелек продуктларын (итне, сөтне, йонны, тирене, йомырканы) гектарлар исәбеннән тапшыру тәртибе кертү турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары Татарстандагы партия оешмаларыннан республикабызның колхозларында җәмагат терлекчелеген һәм кошчылыкны үстерү өчен көндәлек көрәш алып барырга, 1940 нчы елны һәрбер колхозда терлекчелек фермаларында ана терлекләр санын минимумга җиткерүгә һәм кошчылык фермасы булдыруга ирешергә мәҗбүр итә.

Илебезнең оборона сәләтен ныгыту эшенә, югары сыйфатлы атлар үстерүгә гаят зур игътибар биреп, партия активы мәҗбүри рәвештә атлар тапшыру турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын яхшы дип таба һәм республикабыздагы барлык партоешмаларны һәрбер колхозда атлар үрчетүне киңәйтүне тәэмин итү өчен кискен чаралар күрергә чакыра.

Актив җыелышы Казан шәһәренең партия, совет һәм хуҗалык оешмаларын запас частьләр һәм авыл хуҗалыгы инвентаре хәзерләүдә, терлекчелек фермаларын механикалаштыруда, колхозчылар арасында массовый-политик эшне оештыруда республикабызның авыл районнарына кирәкле ярдәмне күрсәтергә мәҗбүр итә.

Партия активы Казан шәһәрендәге барлык партоешмаларга авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасындагы үзгәрешләр турында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының тарихи карарларын хезмәт ияләре арасында киң аңлатуны оештырырга, бу карарларны үтәүгә массаны тупларга куша.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарларын уңышлы үтәү өчен партиянең Татарстан оешмасының большевикларча көрәшәчәгенә, социалистик авыл хуҗалыгының тагын да күтәрелүен тәэмин итәчәгенә Казан шәһәренең партия активы ВКП(б) Үзәк Комитетын һәм сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинны ышандыра.

Яшәсен ВКП(б) ның Ленинче-Сталинчы Үзәк Комитеты!

Яшәсен бөек, сөекле юлбашчыбыз һәм туганыбыз иптәш Сталин!

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА

ЛЕНИН ИДЕЯЛӘРЕ ТОРМЫШКА АШЫРЫЛДЫ

I.

Маркс һәм Энгельс, беренче буларак, иҗтимагый үсеш законнарын, сыйнфи көрәш законнарын ачтылар, беренче буларак, социализм турындагы тәгълиматны утопиядән фәнгә әверелдерделәр. Ленин, марксизмны яңа тарихи шартларда үстереп, аны яңа баскычка күтәрде, пролетариатның һәм аның авангарды—коммунистлар партиясенең—капиталистик дөньяны тетрәтүче идеяләр белән коралландырды.

Аерым алынган бер илдә социализмның җиңүе турында беренче тапкыр Ленин тарафыннан ачылган һәм фәнни төстә нигезләнгән теория—социалистик революциянең, пролетариат диктатурасының, капиталистик чолганыш шартларында социалистик җәмгыять төзүнең нигезе булып тора.

Бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлеге турындагы даһи нәтиҗәгә Ленин империализм эпохасына һәм капитализмның бу эпохага хас булган үсешенә тирәнтен анализ ясау нигезендә килде.

Пролетариатның революцион фәненә нигез салучылар—Маркс һәм Энгельс—пролетариат революциясенең җиңүе мәсьәләсенә ничек карадылар? Капитализмның монополиягә кадәрге стадиясенә анализ ясаганда алар нинди нәтиҗәгә килделәр? Капитализмның бу безгә кадәр булган барлык сыйныфлы җәмгыятьләрне өйрәнгәндә Маркс һәм Энгельс капитализмның һәлак булуы котылгысыз икәнлеген, пролетариат революциясенең [illegible] исбат иттеләр, [illegible] тарихы [illegible] тагын да югарырак булган җәмгыять строе белән—коммунизм белән алмаштырылачагын исбат иттеләр.

Маркс һәм Энгельс пролетариатның, капитализм белән коммунизм арасында күчү чоры бар дип, бу чордагы дәүләт пролетариатның революцион диктатурасыннан башка бер нәрсә дә була алмый дип әйттеләр.

Маркс һәм Энгельс капитализмның котылгысыз һәлакәтен фәнни нигездә исбат иттеләр, ләкин алар пролетариат революциясе аерым алынган бер илдә җиңә алмый дип, мондый революция барлык [illegible] илләрдә, һич югында төп капиталистик илләрдә бер үк вакытта гына була ала дип санадылар.

Маркс һәм Энгельснең бер илдә социализмның җиңүе мөмкин түгеллек турындагы нәтиҗәләре капитализмның монополиягә кадәрге стадиясе чорына гына кагыла иде, ул чор капитализмның күтәрелеп барган чоры иде. Маркснең һәм Энгельснең ясаган нәтиҗәләре социализмның җиңүе турындагы мәсьәләне яңа тарихи шартларда яңача куюны һич тә читкә алып ташламый иде.

Маркс һәм Энгельс бер илдә социализмның җиңүе мөмкин түгеллек турындагы нәтиҗәгә капитализмның җитәрлек кадәр үсмәгән булуы шартларында, пролетариат белән буржуазия арасындагы сыйнфи көрәшнең җитәрлек дәрәҗәдә үсмәгән булуы шартларында килделәр. Маркс һәм Энгельс эпохасы революция алды эпохасы иде, ул чагында әле пролетарийлар революциягә хәзерлек мәктәбен генә үтәләр иде, „пролетариат революциясе әле турыдан-туры практик котылгысызлык түгел иде“ (Сталин). Маркс һәм Энгельс капитализмның шундый чорында яшәделәр ки, ул чагында әле дөнья тәмам бүленмәгән иде, капитализм яңадан-яңа территорияләрне үзләштереп килә иде, дөньяны бүлү өчен көрәш мәҗбүри рәвештә кораллы конфликтларга һәм сугыш катастрофаларына алып бармый иде.

II.

XIX нчы йөзнең ахрында һәм XX нче йөзнең башында капитализм үзенең үсешендә иң югаргы һәм соңгы яңа стадиягә керде, империалистик капитализм булып әверелде. Капитализм үсешендәге бу стадияне тирәнтен һәм һәр яклап өйрәнеп, Ленин, империализмның череп һәм үлеп баручы капитализм икәнлеге турындагы, социалистик революциянең алды икәнлеге турындагы нәтиҗәгә килде. Капитализм үз үсешенең бу стадиясендә прогрессивтан реакцион булып әверелде, житештерүче көчләрнең алдагы үсеше юлында тоткарлык булып әверелде.

Капитализм үсешнең монополия стадиясенә күчү белән дөньяны бүлү тәмам булды. Базарлар өчен, капитал һәм товар чыгару теләге белән территорияләр өчен, чимал чыганаклары өчен империалистик илләрнең көрәше үткен характер алды. Империалистик илләрнең кайберләренең яңа колонияләр, яңа базарлар һәм чимал чыганаклары алырга омтылулары талап алынган җирләрне кулларында тотып калырга омтылучы башка империалистик илләрнең ныклы каршылыгына очрады. Империализм эпохасында сугышларның котылгысыз булуы шушыннан килеп чыга. Мондый сугышлар, империализм каршылыкларының нәтиҗәсе буларак, капитал фронтының йомшавына китерәләр, империализмның бөтен системасын тетрәтә торган тирән революцион кризисларны китереп чыгаралар.

Империализм эпохасында капитализмның үсеше гаять дәрәҗәдә тигезсез һәм сикерешләр белән бара. Империализм эпохасында капитализмның экономик һәм политик үсешенең тигезсез булуы иң үткен формаларга керде, капиталистик фронтның таркалуын күрсәтүче хәл иткеч фактор булып әверелде.

Ленин, беренче буларак капитализмның экономик һәм политик үсешенең империализм эпохасында кискенлек белән көчәя торган тигезсез үсеше законын ачты. Шушы законнан чыгып, Ленин, социализмның башта аз гына һәм хәтта аерым алынган бер генә илдә дә җиңүе мөмкинлеге турындагы һәм социализмның барлык илләрдә дә бер үк вакытта җиңүе мөмкин түгеллеге турындагы нәтиҗәне нигезләде. Бу, империализм эпохасындагы социалистик революция турындагы төгәлләнгән, яңа теория иде. Ленин үзенең „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы“ исемле, 1905 нче елны язылган әсәрендә бу теориянең нигезләрен беренче тапкыр салды, бу теориянең тәмам төгәлләнеп җитүе исә 1915 нче елны булды. „Европа Кушма Штатлары лозунгысы турында“ гы мәкаләсендә Ленин болай дип язды:

„Экономик һәм политик үсешнең тигезсезлеге капитализмның һич шиксез законы ул. Моннан, социализмның башта аз гына илләрдә, яки хәтта аерым алынган бер генә капиталистик илдә җиңү мөмкинлеге килеп чыга. Бу илнең җиңеп чыккан пролетариаты капиталистларны экспроприацияләп һәм үзендә социалистик производство оештырып, башка илләрнең изелгән сыйныфларын үзенә тартып... калган капиталистик дөньяга **каршы** күтәрелер иде“ (том XVIII, бит—232—233).

Лениннең „Пролетар революциянең хәрби программасы“ дигән исем астында 1916 нчы елны язылган мәкаләсендә социализмның башта бер илдә яки берничә илдә җиңүе мөмкинлеге турындагы теория тагын да үстерелде.

Бу мәкаләсендә Ленин болай дип язды: „Капитализмның үсеше төрле илләрдә гаять дәрәҗәдә тигезсез бара. Товар производствосы булганда башкача булырга да мөмкин түгел. Моннан социализм **барлык** илләрдә дә бер үк вакытта җиңә алмый дигән котылгысыз нәтиҗә чыга. Ул башта бер яки берничә илдә җиңәчәк, ә калганнары бер кадәр вакыт буена буржуаз яки буржуазиягә кадәрге илләр булып калачаклар. Бу, кытыршылыкларны гына түгел, бәлки социалистик дәүләтнең җиңеп чыккан пролетариатын тар-мар итүгә башка илләрдәге буржуазиянең турыдан-туры омтылышын да китереп чыгарырга тиеш. Мондый хәлләрдә безнең тарафтан сугыш законлы һәм гадел булыр иде, бу, социализм өчен, башка халыкларны буржуазиядән азат итү өчен сугыш булыр иде“ (том XIX, бит—325).

Ленин бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлекне һәм социализмның барлык илләрдә бер үк вакытта җиңүе мөмкин түгеллекне исбат итте.

„Марксизмга каррикатура турында“ һәм „империалистик экономизм“ турында 1916 нчы елның октябрь ахрында язылган һәм беренче тапкыр 1924 нче елны „Звезда“ журналында басылган әсәрендә Ленин болай дип язды: капитализмның үсеше тигезсез булганлыктан, „илләрнең күпчелеге һәм җир йөзе халкының күпчелеге хәзергә кадәр әле үсешнең хәтта капиталистик баскычында да тормаганлыктан яки аның башлангыч баскычында гына торганлыктан“ социалистик революциянең барлык илләрдә бер үк вакытта булуы мөмкин түгел. Социализмның барлык илләрдә бер үк вакытта җиңүе турында хыяллану, димәк, „социализмны грек календына кадәр, ягни бер кайчан да булмаслык итеп кичектерү“ дигән сүз (том XIX, бит—220—221).

Ленин теориясе болай дип өйрәтә: империализм фронты аның иң йомшак урнында, эчке һәм тышкы каршылыклар иң күп булган урында, пролетариат белән буржуазия арасында сыйнфи көрәш иң кискенләшкән урында, пролетариат берләшкән һәм туплланган урында һәм аның капиталга каршы көрәшенә алдынгы революцион теориясе булган алдынгы партия җитәкчелек итә торган урында, пролетариат үз артыннан хезмәт иясе крестьяннәр массасын ияртеп алып бара торган урында өзелергә мөмкин. Шушындый шартлар булганда теге яки бу илнең пролетариаты үзенең милли буржуазиясе властен бәреп төшерә ала һәм капиталистик чолганыш шартларында үз көчләре белән социалистик җәмгыят төзи ала.

Бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлеге турындагы Ленин теориясе марксистик фәнгә иң кыйммәтле хәзинә булды.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“нда болай диелгән: „Әгәр дә Ленин марксизмның хәрфе алдында тукталып калган булса иде, әгәр дә марксизмның иске нәтиҗәләреннән берсен алып ташларга, аны яңа тарихи обстановкага туры килә торган яңа нәтиҗә белән, аерым алынган бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлеге турындагы нәтиҗә белән алмаштырырга Лениннең теоретик батырлыгы җитмәгән булса иде, партия, безнең революция, марксизм ни хәлдә булыр иде? Партия караңгылыкта адашып йөргән булыр иде, пролетар революция җитәкчелектән мәхрум калган булыр иде, марксизм теориясе загыйфләнә башлаган булыр иде. Пролетариат оттырган булыр иде, пролетариатның дошманнары откан булырлар иде“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 404 нче бит).

Социализмның бер илдә җиңүе мөмкинлеге турындагы Ленин теориясе бик яхшы рәвештә акланды. Безнең илебездә, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, 1917 нче елны социалистик революция җиңде. Империализм фронты беренче тапкыр Россия пролетариаты тарафыннан өзелде. Патша Россиясе империализм чылбырында иң йомшак буын булып чыкты, чөнки анда империализмның эчке һәм тышкы каршылыклары иң күп дәрәҗәдә тупланганнар иде. Россиядә эшчеләр сыйнфы иң революцион сыйныф булып чыкты, аңа коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән большевиклар партиясе җитәкчелек итте, революцион крестьяннәр эшчеләр сыйнфы артыннан бардылар. Россиянең эшчеләр сыйнфы Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, революцион юл белән үзенең милли буржуазиясен бәреп төшерде һәм үзенең политик өстенлеген урнаштырды. Социализмның бер илдә җиңүе мөмкинлеге турындагы Ленин теориясе пролетариат диктатурасы өчен, социализм өчен көрәштә большевиклар партиясе өчен куәтле идея коралы, бөек компас булды.

III.

Социализмның бер илдә җиңүе турындагы Ленин теориясенә троцкичылар, бухаринчылар, буржуаз милләтчеләр ярсулы һөҗүмнәр ясадылар. Ленин үлгәннән соң бу һөҗүмнәр аеруча үткен төс алдылар. Марксизм-ленинизм дошманнары, эшчеләр сыйнфының барлык һәм һәр төрле дошманнары Лениннең бер илдә социализм төзү турындагы теориясен күмеп куярга, социалистик төзелеш эшен өзәргә, капитализмны яңадан урнаштырырга маташтылар. Троцкичы-зиновьевчы һәм башка төрле хиянәтчеләр, яшренү теләге белән, марксизмның бер илдә социализмның җиңүе мөмкин түгеллеге турындагы искергән, гомрен үткәргән положениесенә таянып, үзләренең хиянәтчел эшләрен каплау өчен марксизмнан файдаланырга маташтылар.

Ленинизм дошманнарына каршы көрәштә иптәш Сталин Лениннең бер илдә социализмның җиңүе турындагы теориясен саклап калды, аның эчтәлеген даһиларча нигезләде, аның барлык якларын иҗтимагый үсешнең яңа шартларында—капитализмның гомуми кризисы шартларында һәм җиңүле социалистик төзелеш шартларында үстерде. Сталин идеяләренең бөтен байлыгы, бер илдә социализмның җиңүе турындагы теориягә иптәш Сталин тарафыннан кертелгән барлык яңалыклар шул кадәр бөек һәм әһәмиятле ки, бу теория бик хаклы рәвештә Ленин — Сталин теориясе дип атала.

Иптәш Сталин Лениннең бер илдә социализмның җиңүе турындагы теориясенең халыкара әһәмиятен бөтен күләме белән нигезләде, пролетариатның социалистик революциядәге милли бурычлары белән аның интернациональ бурычлары арасындагы аерылгысыз элемтәне билгеләде, социализм төзелеше чорында партия җитәкчелегендә илебезнең эшчеләр сыйнфы хәл итәргә тиеш булган бурычларны чиктән тыш ачыклык белән куйды.

Партиянең XVIII нче съездында ясаган докладында, илебездә социализмның төзелүе тәҗрибәсенә таянып, иптәш Сталин капиталистик чолганыш шартларында да безнең илебездә коммунизмның җиңүе мөмкинлеген нигезләде, коммунизмның җиңүе өчен конкрет юлларны һәм средстволарны билгеләде, социализмнан коммунизмга күчү чорына гына түгел, бәлки коммунизм чорына да,—әгәр дә ул вакытта әле капиталистик чолганыш сакланып калса,—Совет дәүләтенең ролен һәм бурычларын билгеләде.

Капиталистик чолганыш шартларында бер илдә коммунизм төзүнең мөмкинлеге турында иптәш Сталинның тәгълиматы—марксизм-ленинизм хәзинәсенә иң зур байлык, марксистик-ленинчел революцион фәннең баюы һәм үсүе.

IV.

Бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлеге турындагы Ленин—Сталин теориясенә таянып, без социализмны нигездә төзеп җиткердек һәм ул халыкның көнкүрешенә керде.

Безнең илебез беренче булып социалистик революцияне башлады, беренче булып социализм төзүне тәэмин итте һәм кешелек дөньясы өчен эксплоататорлардан һәм эксплоатациядән башка бәхетле һәм шатлыклы тормышка бару юлын ачты. Эксплоататорларның һәм аларның агентларының—эсерларның, меньшевикларның, буржуаз милләтчеләрнең, троцкичы-бухаринчы кабахәтләрнең каршылык күрсәтүләрен җиңеп, максатка бару юлындагы һәр төрле киртәләрне большевикларча җимереп, ачлыкны һәм салкынны, гражданнар сугышының һәм чит ил интервенциясенең авыр елларын җиңеп,—илебезнең халыклары тырыш хезмәт белән социализмның якты бинасын төзеделәр. Ленин—Сталин партиясе күләме ягыннан гаять дәрәҗәдә зур булган иҗад эше үткәрде.

Кешелек тарихында әле безнең илебездә булган кебек шундый эш күләмнәре, шундый үсеш темплары, шундый алга таба хәрәкәт булганы юк иде. Бөек социалистик революция илебезнең халыклары каршында матур перспективалар ачты, аларның тормыш көчләренә, аларның хезмәткә, коммунистик җәмгыят төзелешенә булган омтылышларына киң юл ачты.

Безнең илебез чын магнәсе белән танылмаслык ил булып әверелде.

Эксплоататор сыйныфларны һәм хуҗалыкның барлык тармакларында җимереклекне бетереп, безнең илебез шундый үсеш юлын үтте һәм шундый төзелеш күләмнәре күрсәтте ки, бөтен нәрсәне буржуаз җәмгыят үсеше ягыннан карап кына үлчәргә гадәтләнгән кешеләрнең, безнең илебезнең үсеш шартларын белмәүче кешеләрнең, социалистик революция тарафыннан тудырылган хәрәкәтләндерүче көчләрне белә алмаучы кешеләрнеңбашларына бу темплар һәм күләмнәр сыя да алмыйлар.

Эшчеләр сыйнфы диктатурасы елларында безнең илебез куәтле индустриаль держава булып, иң эре социалистик игенчелек иле булып, социалистик культурасы көчле рәвештә үсә торган ил булып, халык талантларының чәчәк атуы иле булып әверелде. Производство техникасы һәм промышленностьның үсеш темплары өлкәсендә без аеруча алга киткән капиталистик илләрне куып җиттек һәм узып киттек.

Ленин илебезнең дөньяда алдынгы индустрия тудыра алырлык, капиталистик дөньяга бәйсез булган социалистик экономика тудыра алырлык эшчеләренең һәм крестьяннәренең иҗад көчләренә чиксез ышанды. Ленин безнең илебездә социализм төзү өчен кирәк булганнарның бөтенесенең дә барлыгын фән нигезендә исбат итте.

Лениннең электрлаштыру нигезендә илне индустрияләштерү турындагы васыятләре һәм идеяләре иптәш Сталинның классик әсәрләрендә тагын да үстерелделәр. Иптәш Сталин Лениннең илебезне куәтле индустриаль державага әйләндерү турындагы барлык положениеләрен һәр яклап үстерде, илне индустрияләштерү буенча киң план төзеде, аны троцкичы-бухаринчы капитализм реставраторларына каршы, халыкның иң явыз дошманнарына каршы каты көрәшләрдә саклап калды һәм аның тормышка ашырылуына ирешге.

Вак крестьян хуҗалыгын социалистик нигездә үзгәртү буенча булган кооператив план Ленин фикренең иң даһи иҗады. Лениннең соңыннан иптәш Сталин тарафыннан тагын да үстерелгән һәм тормышка ашырылган кооператив планы—авылда социализм төзүнең бердәнбер дөрес планы.

Социализм өчен көрәштә үзебезнең авыл хуҗалыгыбызны тамырыннан ук үзгәрттек. Борынгы техникага нигезләнгән 24,8 миллион вак һәм бик вак хуҗалыклар урнына алдынгы техника белән коралланган 242,4 мең эре колхоз хуҗалыгы төзелде.

Партиянең XVIII нче съездында иптәш Сталин болай диде: „Димәк, безнең игенчелегебез иң эре һәм механикалаштырылган игенчелек кенә түгел, һәм димәк, иң товарлыклы игенчелек кенә түгел, бәлки башка кайсы илнең генә игенчелегенә караганда да хәзерге заман техникасы белән нык коралланган игенчелек“.

Илне индустрияләштерү һәм крестьян хуҗалыгын коллективлаштыру турындагы Ленин—Сталин идеяләре, алар—капиталистик чолганыш шартларында торучы аерым алынган бер илдә социализм төзүнең сугышчан программасы. Ленин һәм Сталин бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлекне фән нигезендә исбат итеп кенә калмадылар, бәлки социализмның җиңүе буенча большевиклар партиясе кулына конкрет план да бирделәр.

V.

Шәһәрдә һәм авылда социализмның җиңүе Совет җәмгыятенең сыйнфи структурасын үзгәртте. Эксплоататор сыйныфлар бетерелделәр, эшчеләр һәм крестьяннәр моннан элек кешелек тарихында бөтенләй булмаган яңа сыйныфлар булып әверелделәр. Совет интеллигенциясе тамырыннан үзгәрде. Шушы барлык үзгәрешләр нәтиҗәсендә, „эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәр арасындагы, шулай ук бу сыйныфлар белән интеллигенция арасындагы чикләр җуела баралар, ә иске сыйнфи үзгәлек (исключительность) бетә бара. Бу—шушы социаль группаларның арасы якынайганнан якыная бара дигән сүз“ (И. Сталин. ССР Союзының Конституциясе турындагы доклад. 15 нче бит).

Эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең барлык дошманнарына каршы көрәштә социализмның илебез халыклары тарафыннан ирешелгән җиңүләре бөек Сталин Конституциясендә язылганнар. Бу—дөньяда иң демократик Конституция, ул СССР гражданнарына, закон тәртибендә, хезмәткә, ял итүгә, белем алуга һәм картлыкта тәэмин ителүгә хокукны гарантияли.

Социализм өчен көрәш нәтиҗәсендә без милли изүне бетердек, СССР да яшәүче халыклар арасында үзара ышаныч урнаштырдык, барлык халыкларның культурасын формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураны үстерү өчен шартлар тәэмин иттек. СССР халыкларының йөзе тамырыннан үзгәрде, алар арасында дуслык һәм туганнарча бергәләшеп эшләү урнашты.

Иптәш Сталин болай диде: „Нәтиҗәдә безнең хәзер тәмам оешып җиткән һәм бөтен сынаулардан үткән күп милләтле социалистик дәүләтебез бар, аның ныклыгына җир йөзенең теләсә нинди өлешендәге теләсә нинди милли дәүләт сокланырлык“ (шунда ук, 17—18 нче бит).

Эшчеләр, крестьяннәр һәм хезмәткәрләр арасыннан үзебезнең күп санлы социалистик, халык интеллигенциясе кадрларын тудыру—социализм өчен көрәштә эшчеләр сыйнфы диктатурасының бөек казанышы булды. II нче Интернационал партияләренең „теоретиклары“, әгәр дә пролетариат алдан ук, капиталистик строй шартларында ук, производство процессына җитәкчелек итә алырлык оештыручылар, җитәкчеләр, белгечләр кадрлары хәзерләмәсә, ул властьны үз кулына ала алмаячак һәм аннан да бигрәк аны үз кулында тотып кала алмаячак дигәннәр иде. Социалистик төзелеш практикасы аларның бу сөйләнүләрен кире какты. Болар кебек бөтенләе белән капиталга сатылган „теоретик“лардан һәм „социалистлар“дан Ленин ачы итеп көлде.

Ленин, әгәр дә социалистик революциянең җиңүе өчен культураның маглүм дәрәҗәдә булуы кирәк икән, ул вакытта ни өчен башта алпавытлар һәм капиталистлар властен бәреп төшереп, пролетариат диктатурасы урнаштыру кебек чарадан башламаска, ә соңыннан социалистик төзелеш барышында культура кадрлары булдырмаска, массаның культура дәрәҗәсен күтәрү эшен гаять зур адымнар белән алга алып бармаска,—диде.

Безнең илебездә социализм төзелеше тәҗрибәсе Совет власте нигезендә илне идарә итүне юлга сала алырлык культура кадрлары тудыру буенча Ленин—Сталин юлының бердәнбер дөрес юл икәнлеген ачык күрсәтте. Большевиклар партиясе Ленин—Сталин юлы белән барды һәм кадрлар хәзерләү эшендә бөтен алдынгы, прогрессив кешелек дөньясы сокланырлык зур уңышларга ирешге.

Безнең социалистик революциябез халыкка азатлык биреп кенә калмады, бәлки таза һәм культуралы тормышның үсүе өчен материаль шартларны да тәэмин итте. Совет власте елларында безнең илебездә күп санлы эшчеләр сыйнфы үсте, аның материаль-культура хәле үткән заманга чагыштырганда үлчәүсез күтәрелде.

Колхозларга кергән ярлылар һәм урта хәлләләр тәэмин ителгән кешеләр булып әверелделәр. Колхозчы крестьяннәрнең материаль хәле үсү белән бергә, культура дәрәҗәләре дә үсте. Хуҗалыкның социалистик системасы эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең материаль һәм культура шартларын якынайтты. Шәһәр белән авыл арасындагы каршылык кызу темплар белән бетерелә. Авыл хуҗалыгы хезмәте торган саен күбрәк дәрәҗәдә индустриаль хезмәтнең бер төренә әверелеп бара. Безнең илебездә хезмәт намус эше, дан, батырлык һәм геройлык эше.

Социализмның җиңүе Советлар Союзының экономик һәм хәрби куәтен, аның халыкара авторитетын ныгытты. Империалист интервентларның безнең җиребезгә кереп тулган заманнары, житештерүче көчләрне җимергән, халыкны талаган, халыкның иң яхшы улларын кырган заманнары мәңгегә югалды. Хәзер безнең коралланган көчләребез илебезнең изге җиренә кул сузарга батырчылык иткән нинди генә дошманга да кискен отпор бирергә сәләтлеләр.

Җиңеп чыккан социализм нигезендә Совет җәмгыятенең мораль-политик бердәмлеге, халыкларның дуслыгы һәм совет патриотизмы ныгыды. Социализм нигездә төзелеп җитте, илебез үсешнең яңа полосасына, сыйныфсыз социалистик җәмгыят төзелешен төгәлләү һәм социализмнан коммунизмга теземле рәвештә күчү полосасына керде.

Һәм без бернинди кыенлыкларга һәм киртәләргә дә карамастан коммунизмны төзербез, аның балкып торган югарылыкларына килербез. Безгә җәмгыят үсеше законнары белән коралланган, коммунистик җәмгыят төзү турындагы Ленин—Сталин теориясе белән коралланган бөек большевиклар партиясе, Ленин—Сталин партиясе җитәкчелек итә. Марксизм-ленинизм идеяләре бөтен дөньяда җиңәрләр. Капитализм, һич шиксез, пролетар революцияләрнең ударлары астында җимерелер һәм кешелек дөньясы эксплоататорлардан һәм эксплоатациядән мәңгелеккә азат булыр.

Ф. Кошелев.

В. И. Лениннең тууына 70 ел тулуга карата. Рәсемдә: В. И. Ленин I нче Бөтенроссия крестьян депутатлары съездында. Май 1917 ел. Художник П. Васильев рәсме. (В. И. Ленин Үзәк музее).

СОҢГЫ ПОЧТАДАН

Тупас бер ялгыш турында

Сүз колхозлардагы даими звенолар турында бара. Хезмәтне даими звено тәртибендә оештыру югары иген уңышы өчен көрәштә хәл иткеч чараларның берсе булып тора. Бу, бәхәссез, шулай һәм моны практика үзе күптән раслады инде.

Ләкин кайбер районнарда һәм аерым колхозларда даими звеноларны оештыруда кустарьчылык хөкем сөрә.

Даими звеноларны ничек оештыру турында партия һәм хөкүмәт күрсәтмәләре нигезендә аңлату эше алып бару, ялгышларны вактында төзәтү—газеталарның әһәмиятле бурычы. Ләкин, кызганычка каршы кайбер газеталар даими звенолар турында укучыларга үзләре үк ялгыш, алай гына да түгел, хәтта партия күрсәтмәләренә капма-каршы килә торган мәкаләләр урнаштыралар.

Менә „Яш Сталинчы" газетасының (ВЛКСМ Өлкә Комитеты органы) 1940 нчы ел, 19 нчы апрель номеры. Газета бу номерында Октябрь районы, „Ерепкино" колхозының ефремовчы звено җитәкчесе Семен иптәш Улаевның „Безнең звено" исемле мәкаләсен урнаштырган.

Иптәш Улаев үзенең бу мәкаләсендә, звенога 11 кеше, 10 ат, 1 чәчү машинасы һәм башка инвентарьлар беркетелүен әйтә. Ә асылда, даими звенога ат та, инвентарь да беркетелмәскә тиеш. Чөнки атлар һәм инвентарьлар бригадага беркетелә, ә звено бригаданың бер өлеше ул.

Аннан соң шунсы гаҗәп, иптәш Улаев звенога өч гектар җир беркетелүен һәм анда бодай чәчеләчәген күрсәтә. Моңсын инде аңлавы бөтенләй кыен. 11 кеше һәм 10 ат белән бу 3 гектарлык мәйданда звено нәрсә генә эшләр икән?!

Иптәш Улаев звеносы дөрес оештырылмаган. „Яш Сталинчы" газетасы иптәш Улаев мәкаләсен урнаштырып тупас ялгыш эшләгән. Хата зур. Кичекмәстән төзәтергә кирәк.

Авыл хуҗалыгы өчен яңа кадрлар

Яңа тракторчылар хәзерләү өчен Татарстан МТС лары янында курслар оештырылган иде. Курсларга барлыгы 4.500 кеше кабул ителде. Шулардан 900 ләп кеше курсларны тәмам итеп чыкты инде. Калганнары апрель - май айларында укып чыгалар.

МТС лар янында ачылган курсларда 350 дән артык шофер хәзерләнә. Бу шоферлар МТС ларда һәм колхозларда эшләячәкләр. Комбайнчылар хәзерләү мәктәпләрендә бер меңгә якын комбайнчы һәм 500 дән артык комбайнчы ярдәмчеләре укып чыга.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

Иртә культуралар чәчүне төгәлләделәр

ПУЧЫ, 21 апрель. (Телеграф буенча). Калинин районының „Нептун", „Чишмәле тау", „Таш елга", Тельман һәм Чапаев исемендәге колхозлары 20 нче апрельдә иртә культуралар чәчүне яхшы сыйфатлы итеп төгәлләделәр.

Герасимов.
Район җир бүлеге мөдире.

Мөслим районының „Кызыл бүләк" колхозы 20 нче апрельдә 242 гектар мәйданда иртә культуралар чәчүне төгәлләде. Шулай ук районның „Парижская Коммуна", „Корыч кул" һәм „Трактор" колхозлары да иртә культуралар чәчүне төгәлләделәр. (ТатТАСС).

* * *

Тымытык районы, Үчәлле авыл советына караган „Кызыл Йолдыз" колхозы (председателе комсомолец иптәш Әхметов) иртә культуралар чәчүне төгәлләде. Хәзер колхозда соңгы культуралар өчен туфрак хәзерләү бара.

М. Халиков.

ТРАКТОРЛАРНЫ ЭШСЕЗ ТОТАЛАР

ЧЕПЬЯ, 21 апрель. (**Телефон буенча**). Районның „Беренче Май" колхозы язгы сөрү һәм культивацияләү эшләренә кереште. „Кызыл юл" колхозы 22 гектар тырмалады һәм 13 гектар сөрде. Бу колхозның 2 нче бригадасы членнары Насихов һәм Сабиров иптәшләр тырмалауда 3,5 гектар норманы 4 гектар итеп үтиләр.

„Крестьянская газета" колхозында Чурпанов һәм Низамов иптәшләрнең бригадалары солы чәчәләр. Бу колхозда туфрак күптән өлгергән. Ләкин бу колхозда Димитровский МТС ының тракторлары ягулык булмаганлыктан, эшкә керешми торалар. МТС та ягулыкны алдан ташып куюны кайгыртмаганнар.

Х. Галләмев.



Питрәч районы Кулай совхозы тракторчысы И. Л. Куликов үзенең тракторын совхоз кырларына алып чыга. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Киләләр дә китәләр...

ЧИСТАЙ. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). Чистай районының „Красный партизан" колхозы бригадирлары Данилин, Варламов, Филин, агротехник Сергей Захватов, трактор отряды бригадиры Гаршин һәм колхоз председателе Захватов иптәшләр кыр эшләренә керешү алдыннан үткәрелгән киңәшмәдә озын-озын речьләр белән чыктылар. Аларның речьләре чәчүне иң тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп үткәрү мәсьәләсенә багышланган иде. Соңгы сүзне ВКП(б) райкомы вәкиле иптәш Царев сөйләде. Ул:

— Әйе, иптәшләр, эш иң яхшы сыйфатлы итеп чәчәргә, бурыч шундый,—дип ашыгып-ашыгып кына „зарядка" бирде дә Чистайга кайтып китте.

„Зарядка" алган бригадирлар 15 нче апрельдә үз участокларында эшкә керештеләр. Сүз, үз-үз, ә эш башка нәрсә. Иптәш Филин бригадасындагы сөрүчесе Егорчев 2—3 сантиметрга сай сөрде. Иптәш Варламов бригадасында иптәш Захаров тунга сөрелгән җирне [illegible] культивацияләде. Бу көн шулай үтте.

Вәкил булгач, булырга дигәндер инде. Иптәш Царев 16 нчы апрельдә тагын колхозга килде.

— Эшләр барамы?—диде ул, бригадирларга. Алар:

— Бара, бара, тыныч бул иптәш Царев,—дип җавап кайтардылар. Бу сүзләрне ишеткәч иптәш Царев үзен тагын да ирекенрәк сизеп куйды, һәм шунда шоферга машинасын Чистай юлына борырга кушты. Ә кич колхозга сыйфат бозу кичәгечә дәвам итте. Царев киткәч озак та үтмәде, колхозга Чистай МТС ы директоры иптәш Фадеев килде. Ул да болай үзе беренче сүзне чәчүдән башлады.

— Чәчү ничек бара?—диде, һәм:

— Хәзергә яхшы бара,—дигән җавапны алды. Шуннан соң ул да аны-моны сорашып тормады, машинасына утырып кирге колхозга китте.

Иптәш Фадеев колхоз правлениесе янындагы кунаклык көзеннән киткәч, Галактионов авылының икенче урамында район җир бүлеге мөдире иптәш Бариев килеп керде. Ул да кайбер саннар алды да маршрутын буенча алга хәрәкәт итте. Ә колхоз басуында сай сөрү, начар тырмалау кабатланды.

17 нче апрельдә Чистайдан Госстрахсемфонд агрономы иптәш Миронов килде. Ул башкалардан да артыграк җибәрде. Колхозда хәзергә дөрес оештырган вакытта иртә культуралар чәчүне 7—8 эш көнендә төгәлләргә мөмкин. Ул менә 12 көнгә төгәлләргә „планлаштырып" китте.

„Красный партизан" колхозы членнары:
— Киләләр дә китәләр, бик аз ярдәм итәләр,—диләр. Бу бик дөрес. Нәрсә буенча җибәрелгән кебек бер-бер артлы вәкилләр килеп киткәч колхоз эш үзгәрмәде соң? Юк. Сыйфат бозу һаман да кабатлана. Тракторчы Шмагин тунга сөрелгән җирне культивацияләгәндә бик күп урыннарда чи калдырган. Иптәш Егорчев сай сөрү. Петров начар тырмалый. Эш бик сүлпән бара. Тулы 3 көндә 2 трактор, 9 сабан, 6 тырма белән бары 15 гектар мәйданда туфрак эшкәртелгән.

Колхозда агитация-масса эшләре дә оештырылмаган. Кыр станын бөтенләй онытканнар. Кыр эшләре башланганнан бирле бер генә стена газетасы да чыгарылмаган. Кычкырып газета укулар һәм беседалар үткәрелми. Сөрүчеләр, тырмачылар һәм чәчүчеләр арасында социалистик ярыш оештырылмаган. Райком вәкиле иптәш Царевка:

— „Красный партизан" колхозы белән кемнәр ярышканы?—дип сорау биргәч:

— „Аврора" колхозы белән ярыша,—ди.
„Аврора" колхозы белән „Красный партизан" колхозы белән төзелгән ярыш договорын сорагач, бөтенләй аптырап калдылар.

— „Красный партизан" колхозы белән безнең бер вакытта да ярышканыбыз юк. Без „Кама" колхозы белән ярышабыз,—дип җавап бирделәр.

Колхоздан газета гастрольләре итүнең, оператив җитәкчелек күрсәтмичә, куналсез йөрүләренә нәтиҗәләре шул шундый. *К. Исламов.*

Бәрәңге яровойлаштыруны өзәләр

ДӨБЪЯЗ, 21 апрель. (**Телефон буенча**). Районның күп кенә колхозлары әле шушы көнгә кадәр бәрәңге яровойлаштыру эшенә керешкәннәре юк. Ворошилов исемендәге колхозда 100 центнер бәрәңге яровойлаштырылырга тиеш. Колхоз председателе Гарипов, агротехник Хәбибуллин иптәшләр урын юк дигән сылтау белән бу эшне өзәләр. Бүгенге көнгә бары 11 центнер гына бәрәңге яровойлаштырырга салынган. „Маяк № 2" колхозында да шундый ук хәл.

МТС агрономы иптәш Галләмев бу хәлне белсә дә, бер чара да күрми. Район җир бүлеге бәрәңге яровойлаштыру һәм уҗым тукландыру эшләренә конкрет җитәкчелек итми, урыннарда эшнең торышы турында бер нәрсә дә белми.

Надыйров.

КОЛХОЗЛАРДА ЯЗГЫ ЧӘЧҮ ЭШЛӘРЕНЕҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН ҖИР ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ СВОДКАСЫ

1940 нчы елның 20 нче апреленә
(Планга карата процентларда)

РАЙОННАР	Барлык чәчелгән сабан культуралары	РАЙОННАР	Барлык чәчелгән сабан культуралары	РАЙОННАР	Барлык чәчелгән сабан культуралары
Көньяк-көнчыгыш районнар		Ворошилов	25,0	Биләр	1,9
Тымытык	39,1	Минзәлә	24,4	Әлки	1,2
Ютазы	26,2	Чаллы	10,0	Чистай	1,0
Азнакай	23,6	Әгерҗе	5,6	Тельман	0,6
Сарман	18,6	Мамадыш	5,2	Барлыгы:	2,5
Баулы	14,1	Бондюг	4,8	*Көнбатыш районнар*	
Әлмәт	12,5	Кызыл Йолдыз	4,7	Лаеш	2,7
Заинский	12,0	Кызыл Бор	4,7	Буденный	2,0
Бөгелмә	9,1	Балык Бистәсе	2,8	Зур Тархан	1,4
Беренче Май	5,3	Тәлче	2,5	Кама Тамагы	1,4
Акташ	4,6	Саба	0,4	Буа	0,5
Барлыгы:	13,0	Барлыгы:	10,0	Кайбыч	0,5
Төньяк районнар		*Кама арты районнары*		Питрәч	0,4
		Ширәмәт	9,3	Тәмте	0,1
Мөслим	39,7	Яңа Чишмә	6,0	Барлыгы:	0,6
Калинин	39,0	Октябрь	6,0	Татарстан буенча барлыгы:	7,0
Актаныш	26,4	Кызыл Армия	3,7		

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

СУГЫШЧЫЛАР ҺӘМ КОМАНДИРЛАР АРАСЫНДА

Бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның туууына 70 ел тулган көнне Казан гарнизоны подразделениеләренең сугышчылары һәм командирлары 22 нче апрельдә киң рәвештә билгеләп үттеләр.

Подразделениеләрнең берсендә иртә белән политрук Якубовский сугышчылар һәм кече командирлар арасында политик информация үткәрде. Ул аларга Владимир Ильичнең тормышы һәм эше турында сөйләде, Ленин турындагы художество әсәрләреннән берничә өзекне укып чыкты.

Кызыл армеецлар тулай торагының Ленин бүлмәсендә: „Ленин" дигән темага яхшы итеп витрина оештырылды. Беседадан соң сугышчылар витринадагы фотографияләрне һәм рәсемнәрне зур игтибар белән карадылар, Ленин әсәрләреннән алынган аерым өзекләрне укыдылар.

Командир иптәш Мишов кече командирлар арасында Ленин турында беседа үткәрде. Аннан соң ул Н. К. Крупскаяның „Ленин турында истәлекләр" дигән китабын коллектив рәвештә укуны оештырды. Кече командир Ставрунов сугышчыларга, Кызыл Армия турында, сугышчылар, командирлар һәм политработниклар турында В. И. Ленинның армый-талмый кайгыртучанлык күрсәтүе турында сөйләде.

Ленин турындагы кинофильмнәрне 363.500 кеше карады

Татарстан хезмәт ияләре Ленин турындагы кино-картиналарны зур кызыксыну белән карыйлар. „Ленин 1918 нче елда", „Ленин Октябрьдә", „Мылтыклы кеше", „Бөек таң" картиналары тамашачылар арасында гаять зур популярлек белән файдаланалар.

Үткән елның июль аеннан алып бу картиналарны Татарстанда 363.500 кеше карады.

ЛЕНИННЕҢ СКУЛЬПТУРАСЫ

Казан скульптуры Счастнев В. И. Ленинның туууына 70 ел тулу көненә, Владимир Ильичнең 17 яшьлек гимназист вактын гәүдәләндергән скульптура ясады. Скульптурага художество осталары тарафыннан югары бәя бирелде. Ленинның бу скульптурасы якын көннәрдә Казан Ленин музей-йортына куелачак.

ШАХМАТ-ШАШКА

„ЯШЛӘР" ҺӘМ „КАРТЛАР" ОЧРАШУЫ

Шахмат-шашка клубы шушы көннәрдә Казан шахматчыларының һәм шашкачыларының кызыклы очрашуын үткәрде. Уен стажлары ягыннан күптәнге уенчылар—„картлар" белән әле соңгы елларны гына оста уйнау дәрәҗәсенә күтәрелгән уенчылар—„яшләр" очрашты.

„Картлар" (шахматчылар) командасында Нәҗметтинов, Колчурин, Косолапов, Хрусталев, Ермолин, Ефремов, Нейков һәм „яшләр" командасында Сайгин, Хенкин, Вельтмандер, Кутуев, Щербаков, Ильясов, Чеплевский иптәшләр уйнады.

Нәҗметтинов—Сайгин һәм Ефремов—Ильясов партияләре ничья белән тәмам булды. Косолапов Вельтмандерны, Ермолин Щербаковны оттылар. Аның каравы, „картлар" дан Колчурин Хенкинга, Хрусталев Кутуевка һәм Нейков Чеплевскийга оттырдылар. Нәтиҗәдә, бу очрашу 4:3 исәбенә яш шахматчыларның җиңүе белән тәмамланды.

Шашкачылар очрашуы, киресенчә, 3,5:1,5 исәбенә „картлар" ның отуы белән бетте. Ивлиев Грудцинны, Андрианов Романовны оттылар, ә Елисеев—Блом, Алакшин—Трофимов, Кириков—Сорокин партияләре ничья белән тәмам булды.

БЕЛДЕРҮ

26 нчы апрель, кич 6 сәгаттә Шәһәр Советының утырышлар залында (35 нче бүлмә) „1940 нчы елда шәһәр төзеклеге" дигән темада лекция үткәрелә. Лектор—Горкомхозның баш инженеры иптәш Казанкин.

Шәһәр Советының һәм район советларының депутатлары чакырылалар.

Редактор урынбасары **И. ҮЗБЕКОВ.**
Зам. редактора **И. УЗБЕКОВ.**

Чит илләрдә

СКАНДИНАВИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

БЕРЛИН, 21 апрель. (ТАСС). Германия армиясе верховный командованиесенең хәбәр итүенә караганда, 20 нче апрельдә кич белән Нарвик якынында дошманның хәрби диңгез көчләре күренгән. Алар Нарвикка озак атып торганнар. Англичаннар гаскәр төшерергә маташмаганнар. Нарвик районында Германия гаскәрләре 8 мең винтовка, 315 пулемет һәм башка сугыш кирәк-яраклары кулга төшергәннәр.

Берген һәм Ставангер районында Германия гаскәрләре үзләре алган территорияне киңәйтүне һәм аны норвегиялеләрнең кечкенә отрядларыннан чистартуны дәвам итәрәләр.

Осло районында Германия гаскәрләре Амотка кадәр һәм Хамардан төньяктарак 50 километрга алга киттеләр. Германия гаскәрләре Гьевикка якынлаштылар.

Хардангер-фиордта Норвегиянең берничә кечерәк сугыш карабы батырылды. 20 нче апрельдә Германия авиациясе Намсос һәм Андалснес якынында англичаннарның гаскәр төшерүләренә комачаулык итте. Андалснес янында англичаннарның крейсерына һавадан бомбалар ташланды. Крейсер батты. Англичаннарның икенче бер крейсеры ярга ташланды. Икенче бер урында 15 мең тонна авырлыгындагы транспортка берничә бомба эләкте. Карабта янгын чыкты. Гаскәрләр ташый торган бер транспорт бомбалар тию нәтиҗәсендә бик нык янтайды. Бу урыннарда җиргә төшкән Англия гаскәрләре бомбага тотылды. Нәтиҗәдә алар күп кенә кешеләрен һәм материалларын югалттылар. Дошманның һөҗүм итү юллары һәм күперләр җимерелде.

Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германиянең Бьернефел якынында булган сугышта катнашкан һәм өч офицердан, 18 солдаттан торган патруле адашып Норвегия—Швеция чигенә барып чыккан. Монда аларны Швециянең чик буе гаскәрләре коралсызландырып интернировать иткәннәр.

ЛОНДОН, 21 апрель. (ТАСС). Хәрби министрлекнең хәбәр итүенә караганда, 19 нчы апрельдә Норвегиядә Англия—Франция гаскәрләре стратегия ягыннан әһәмиятле булган берничә пунктны алганнар. Намсос районында җиргә төшкән Англия гаскәрләре шәһәрдән көнчыгышта ныгыйлар.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Норвегиянең төньягында төшкән Англия—Франция гаскәрләре составында механикалаштырылган частьләр бар. Бу частьләр Норвегиядәге шартларда операцияләр алып бару өчен яраклаштырылганнар.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Норвегия гаскәрләре Тронгеймнан төньяктарак тупланып, Намсоста һәм Тронгеймнан 100 миль ераклыкта—Молдеда төшкән союзниклар гаскәрләре белән элемтә урнаштырганнар. Норвегия гаскәрләре шулай ук союзникларның Тронгеймнан көньяктагы гаскәрләре белән дә элемтә урнаштырганнар. Немецләр Тронгейм тирәсендә оборона ныгытмалары ясыйлар. Алар союзниклар гаскәрләренең Намсостан көньякка таба хәрәкәт итүен туктатырга маташалар.

„Дейли мейл" нең хәбәр итүенә караганда, Молдега төшкән Англия частьләре немецләргә каршы сугыша башлаганнар.

СТОКҺОЛЬМ, 21 апрель. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгының хәбәрендә Англия гаскәрләренең Көнчыгыш Норвегиядә бара торган сугышларда катнашуы әйтелә. Кичә Германия самолетлары Рена һәм Осен шәһәрләренә (Лиллехамердан көнчыгыштарак) яңадан бомбалар ташлаганнар.

ОСЛО, 21 апрель. (ТАСС). Норвегиянең оккупацияләнгән өлкәләренең хөкүмәт советы чит илләрдән кертелә торган каты ягулыкны сатуны тыйган. Промышленность һәм транспорт кирәкләре өчен ягулык сату буенча махсус кагыйдәләр эшләнә.

Германия командованиесе радио тапшыру һәм кабул итү аппаратлары частьләрен сатуны тыйган.

21 нче апрельдә Германия илчесе матбугат вәкилләренә Норвегияне оккупацияләү турында 25 елга договор төзүне немецләрнең таләп итүләре турындагы хәбәрләрнең уйдырма икәнлеген белдергән. Германия илчесе шулай ук немецләрнең Норвегия акчаларын җыюлары турындагы хәбәрләрне дә юкка чыгарган.

ЛОНДОН, 21 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, авиация министрлеге белдерү игълан иткән. Бу белдерүдә кичә төнлә Темза елгасы тамагында Германия самолетларының күренүе әйтелә. Зенит батареяләре самолетларга атканнар. Англиянең берничә истребителе һавага күтәрелгән.

Германиянең юкка чыгаруы

БЕРЛИН, 20 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Берлин даирәләре Нарвик турында Англия һәм Франция радиосы тарафыннан төрле телләрдә тапшырыла торган хәбәрләрнең бер-берсенә капма-каршы булуларына игтибар бирәләр. 19 нчы апрельдә Париждан, инглиз телендә, Нарвиктагы Германия гаскәрләре икегә бүленделәр һәм бер-берсеннән аерылдылар дигән хәбәр тапшырылды. Кич белән Лондон Англия һәм Норвегия гаскәрләре Нарвикка һөҗүмнәрен дәвам иттерделәр дип раслады. Грек телендә Англия самолетларының Нарвикны бомбага тотулары турында хәбәр ителде, ә Лондон немец телендә Нарвикка керү юлларының инде англичаннар кулында икәнлеген тапшырды. Венгриягә Нарвик тирәләренең Германия гаскәрләреннән чистартылуы турында ялган хәбәр алынды.

Германиядә бу хәбәрләрнең алдагы хәбәрләрдән аеруча скромный тонда булулары белән аерылып торуларын, ләкин шулай да чынлыктан ерак икәнлеген белдерәләр, чөнки Нарвик элеккегә кебек үк Германия гаскәрләре кулында. Нарвик районында Германиянең коры җир гаскәрләренең югалтулары шул кадәр аз, бу факт үзе генә дә бу районда зур сугышлар булу турында көнбатыш державаларның хиялый белдерүләрен юкка чыгара.

ГИТЛЕРГА 51 ЯШ ТУЛДЫ

БЕРЛИН, 21 апрель. (ТАСС). Кичә Гитлерга 51 яш тулды. Газеталар Гитлерга багышлап мәкаләләр, Геббельсның зур речен һәм Герингның мөраҗәгатен урнаштырдылар. Германия армиясенең баш командующие Браухич, хәрби диңгез флотының баш командующие Редер һәм хәрби һава флотының баш командующие Геринг гаскәрләргә махсус приказлар чыгардылар.

Казан Коммуналь Төзелеш Инженерлары институты
1940 нчы елда институтка керергә теләүчеләр өчен,
РИСОВАНИЕ ҺӘМ ЧЕРЧЕНИЕ БУЕНЧА ТҮЛӘҮСЕЗ
курслар оештыра
Курсларга керергә теләүчеләр көндез 11 сәгаттән 2 гә кадәр институтның канцеляриясендә языла алалар. Казан, Ершов кыры, 20.
1 нче занятие 24 нче апрель көндез 10 сәгаттә 7 нче мәктәптә үткәрелә (Бутлеров урамы, 7). 669—1

КАЗАН ШӘҺӘРЕ МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ
балалар бакчаларында һәм мәктәпкә кадәр тәрбия — бирү җәйге мәйданчыкларында эшләү өчен —
ТӘРБИЯЧЕЛӘР ХӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА
БЕР АЙЛЫК КУРСЛАР АЧА
Курсларга кимендә 7 класс күләмендә белемле хатын-кызлар алыналар.
Гариза белән бергә, курсларга керүченең автобиографиясе, белеме һәм сәламәтлеге турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Гаризалар шушы ел, 28 нче апрельгә кадәр алына. Казан, Чернышевский урамы, 1, Шәһәр Советы бинасы, икенче кат, 29 нчы бүлмә. 664—1

7 нче май, кич 6 сәгаттә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә институт гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм түбәндәге темаларда халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә
1. Ветеринария фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен Казан Дәүләт Ветеринария институты доценты Н. А. Васнецов. Тема: „Йорт тавыкларында вегетатив нервлар системасы периферик бүлегенең морфологиясе".
Рәсми оппонентлар: фәннәр докторы профессор В. Н. Терновский, фәннәр докторы профессор И. Ф. Иванов һәм фәннәр докторы профессор А. П. Студенцов.
2. Ветеринария фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен Краснодар терлекчелек тәҗрибә станциясенең өлкән фәнни сотрудниги А. А. Фомин. Тема: „Английский нәселле ак эре дуңгызның постэмбриональ чорда үсеше турындагы мәсьәләгә карата".
Рәсми оппонентлар: фәннәр кандидаты доцент Г. В. Крылов һәм фәннәр кандидаты доцент Ф. Ф. Федотов.
Диссертация материаллары белән институт китапханәсендә танышырга мөмкин. 600—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
23, 25, 26, 27 һәм 30 нчы апрельдә көндез һәм кич премьера
ХУҖА НАСРЕТДИН
Бүген „1" штампы сугылган билетлар белән кертелә.
Спектакль кич 8 сәгаттә башлана. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген яңа программа буенча
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ ДӘВАМ ИТӘ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Иртәгә, 24 нче апрельдә
Татар Дәүләт Академия театры бинасында көндез
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Кич—ИРЕК
Коллектив рәвештә килү өчен 29—84 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген—ПРЕМЬЕРА
МЕТЕЛЬ
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Киров районы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
23 һәм 24 нче апрельдә
МАСКАРАД
Кич 8 дә башлана.

ТАТГОСФИЛАРМОНИЯ
23 нче апрельдә Укытучылар йортында | 24 нче апрельдә Кызыл Армия йортында
Бөек рус композиторы
П. И. ЧАЙКОВСКИЙНЫҢ
тууына 100 ел тулуга багышланган
КОНЦЕРТЛАР
циклы башлана
Кич 9 да башлана.
Касса концерт көннәрендә көндез 3 тән кич 9 га кадәр ачык.

Кинотеатр	Фильм
„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 5-30, 7, 8-30, 10 да.	МЫЛТЫКЛЫ КЕШЕ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	ЛЕНИН ОКТЯБРЬДӘ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ЛЕНИН 1918 нче елда
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ВЫБОРГ ЯГЫ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	БӨЕК ТАҢ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1534. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ №1556.